85 нче «Карусель» балаларны эстетик-сәнгать юнәлешендә үстерү эшчәнлеген өстенлекле гамәлгә ашыручы гомумүстерелешле балалар бакчасы
муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

Педагогик советта каралган һәм расланган:

Протокол № 1
«28» 08 2024 ел

Раслыйм:
«Карусель» 85 нчы балалар бакчасы җитәкчесе
Ханнанова Г.Д.
«28» 08 2024 ел

«Карусель» 85 нчы балалар бакчасы җитәкчесе приказы белән кулланылышка тапшырыла
«28» 08 2024 ел . № 261

# 3 нче зурлар (5-6 яшь) төркеменең 2024-2025 нче уку елына эш программасы

Төзүче:
Тимербаева Алсу Реисовна

Яр Чаллы
2024 ел

# Эчтәлек

**1.Максатчан бүлек.**

1.1.Аңлатма язуы.........................................................................................................2
1.2. Программаның максаты һәм бурычлары.................................................................4
1.3 Программаны формалаштыруның принциплары......................................................5
1.4. 5-6 яшьлек балаларның шәхси һәм яшь үзенчәлекләре..............................................6
1.5. Прграмма үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре.........................................7
1.5.1.Максат ориентирлары......................................................................................7
1.5.2.Программаны үзләштерүнең нәтиҗәләрен бәяләү системасы.....................................9
1.5.3. Педагогик диагностика.......................................................................................9
.

**2.Эчтәлек бүлеге**

2.1. Балаларның үсеш юнәлешләренә туры килгән белем бирүэшчәнлеге...................10
2.1.1. Социаль-коммуникатив үсеш өлкәсе......................................................................11
2.1.2. Танып белү үсеш өлкәсе.......................................................................................14
2.1.3. Сөйләм үстерү үсеш өлкәсе...................................................................................15
2.1.4. Нәфасәти үсеш өлкәсе.........................................................................................16
2.1.5. Физик үсеш өлкәсе..............................................................................................17
2.2. Турыдан -туры белем бирү эшчәнлегенең комплекслы-тематик планы................19
2.3. Уен эшчәнлеге......................................................................................................24
2.4.Программаны гамәлгә ашыруның формаларын, ысулларын, алымнарын һәм чараларын тасвирлау.......................................................................................................25
2.5. Белем бирү өлкәләренең ЭРС яраклаштырылган бурычлары.................................30
2.6.Гаилә белән үзара бәйләнеш .................................................................................36
2.7. Шәһәребезнең төрле оешмалары белән аралашу. ...................................................38

**3.Оештыру бүлеге.**

3.1.Предметлы тирәлек мохите оештыру үзенчәлекләре................................................38
3.2. Материаль- техник тулыландыру...........................................................................40
3.3. Фәнни- методик әдәбият исемлеге.........................................................................41
3.4. Көн тәртибе.......................................................................................................... 40
3.5.Зурлар төркемендә белем бирү эшчәнлегенең челтәре...........................................41
3.6. Белем бирү-тәрбия эшен планлаштыру үрнәге........................................................46
3.7. Мәдәни-ял эшчәнлеге (традицион вакыйгалар, бәйрәмнәр, чаралар).....................47
Кыскача презентация...............................................................................................48

# I Максатчан бүлек.

## 1.1 Аңлатма язуы.

Бу программа “Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасы структурасына, Федераль дәүләт таләпләре”нә нигезләнеп, Н.Е.Вераксы, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендәге ”Туганнан мәктәпкә кадәр”төп гомуми мәктәпкәчә яшьтә белем бирү программасына,балалар бакчасының еллык эш планына таянып төзелде.

Оештыручы: Муниципальное образование город Набережные Челны. Функции и полномочия учредителя осуществляет Исполнительный комитет муниципального образования город Набережные Челны.

**Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмасының атамасы:**

«Карусель» исемле балалар

Бакчасы-баланың аң-белемен үстерү үзәге муниципаль бюджет бирү учреңдениясе **Кыскача атамасы** : “Карусель” 85 нче балалар бакчасы МБМББУ.

**Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмасының адресы:**

*РФ субъекты:*ТатарстанРеспубликасы

*индекс*: 423814,

*шәһәр:* Яр Чаллы шәһәре

*урам:Николай Мальнев*

*йорт:* 1нче бина

*шәһәрнең федераль телефон коды:* (8552) *телефон:* 49-32-03,

*факс:* 51-28-28 e-mail: sad85karusel@mail.ru

**Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмасының җитәкчесе:**

Ханнанова Гөлнара Данил кызы

**Программаны тормышка ашыру срогы - 1 ел (2020-2021 уку елы)**

Эш программасы түбәндәге норматив документлар буенча яраклаштырылган:

**Федераль дәрәҗәдә**:

- Федераль закон «Рәсәй Федерациясендә белем алу» от 29.12.2012 г. N 273-ФЗ
- Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирүнең
- федераль дәүләт белем бирү стандартын раслау турында»гы 1155 нче номерлы 2013 ел 17октябрь приказы.
- Закон РТ «Белем алу турында»;
- Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Төп гомумибелем бирү программалары — мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслаутурында» приказы, 30.08.2013, № 1014.
- Россия Федерациясе Баш санитария табибының «СанПиН 2.4.1.3049-13«Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының эш режимы төзелешенә, эчтәлегенә һәм оештырылуынакарата санитарияэпидемиология таләпләре»нраслау турында» карары, 15.05.2013, № 26.

**Региональ дәрәҗәдә**:

– Закон Республики Татарстан от 22 июля 2013 г. № 68-ЗРТ "Об образовании"

– Закон Республики Татарстан "О языках народов Республики Татарстан" № 1560-XII от 8 июля 1992 года

**Җирле дәрәҗәдә**:

МБМББУ 85 нче «Карусель» исемле балалар бакчасының уставы

Алдагы уку елына еллык эш планы

Бүген җәмгыятьтә катлаулы социаль-экономик процесслар бара, белем бирүнең кыйммәтләре һәм максаты тамырдан үзгәрә. Балаларга белем бирүнең бөтен өлкәләрендә дә актив, иҗади, үзенүзгәртергә әзер торучы шәхес тәрбияләү таныла. Балаларның шәхси

һәм социаль мөнәсәбәт позициясен күздә тотып, аларны мәктәпкә әзерләүдән күчү, мәктәпкәчә белем бирү нәтиҗәләренең күзаллавын үзгәртергә булыша. Нәтиҗәлелек: мәктәпкәчә яшьтәге балаларда кызыксынучанлык, активлык, мөстәкыйльлек сыйфатларын формалаштыра; ялгышларны уңышсызлыкларны җиңеп чыгарга зәерлек, яңа белем алырга, стандарт булмаган ситуацияләрдән чыгу юлын эзләргә омтылыш тудыра; үзе сайлаган эшкә җаваплылык, командада эшли белү, үзенә, башкаларга, җәмгыятькә, әйләнә-тирәгә ихтирамлы караш, кайгыртучнлык тәрбияли. Болар барысы да баланы мәктәпкә әзерләп кенә калмый, ә хәзерге җәмгыятьтә уңышлы мөстәкыйль эшләү өчен нигез булып тора. Билгеле, мондый нәтиҗәләргә ирешү өлкәннәрнең фикер йөртүендәге үзгәртеп корулар белән бәйле, педагоглар һәм ата-аналар үзгәртеп коруда үзләре башлап йөрергә тиеш. Шунлыктан, Программа педагог-бала- ата-ана мөнәсәбәтенә ориетлаштырылган.

Норматив документлар.

*Халыкара законнар.*

Балаларның яшәешен, якланышын һәм үсешен тәэмин итү турында Бөтендөнья декларациясе, 1990.

БМО ЮНИСЕФ балалар фонды. Бала хокуклары Декларациясе, 1959.

Бала хокуклары турында Конвенция (Нью-Йорк, 20.11.1989).

*РФ Президенты Указлары*

Россия Федерациясе Президентының «Мәгариф һәм фән өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Указы, 07.05.2012, № 599.

Россия Федерациясе Президентының «2012–2017 елларга балалар мәнфәгатьләренә юнәлтелгән гамәлләрнең Милли стратегиясе турында» Указы, 01.06.2012, № 761. *Федераль законнар*

«Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» Федераль законы, 24.07.1998, № 124-ФЗ.

«Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерүче мәгълүматтан саклау турында» Федераль законы, 29.12.2010, № 436-ФЗ.

«Мәгариф турында Россия Федерациясе Законы» Федераль законы, 29.12.2012, № 273-ФЗ.

*Федераль дәрәҗәдәге приказлар, карарлар, хатлар һәм башка документлар*

Мәгариф оешмалары эшенең сыйфатын бәйсез бәяләү системасын уздыру буенча методик тәкъдимнәр (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан 2013 елның 14 октябрендә расланган). 349

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча методик тәкъдимнамәләрнең юнәлеше турында» хаты, 01.10.2013, № 081408.

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандартын кертүне тәэмин итү буенча чаралар уздыру зарурлыгы турында» хаты, 10.01.2014, № 0810.

Россия Мәгариф күзәтчелеге комитетының (Рособрнадзорның) «Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары турында» хаты, 07.02.2014, № 015222/05382.

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы Гомуми белем бирү департаментының «Мәктәпкәчә белем бирү ФДББСна шәрехнамәләр» хаты, 28.02. 2014, № 08-249.

Россия Федерациясе Хезмәт министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына (ясле, ясле-бакчалар, балалар бакчалары) хезмәт күрсәтү белән мәшгуль персоналның санын билгеләү буенча нормативларны раслау турында» карары, 21.04.1993, № 88.

Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының «СанПиН 2.4.1.314713 «Торак фондының торак бүлмәләрендә урнаштырылган мәктәпкәчә төркемнәргә карата санитария-эпидемиология таләпләре»н раслау турында» карары, 19.12.2013, № 68.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең 2013–2020 елларга «Мәгариф үсеше» дәүләт программасын раслау турында» карары, 15.04.2014, № 295.

Россия Федерациясе Баш санитария табибының «СанПиН 2.4.1.3049-13 «Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының эш режимы төзелешенә, эчтәлегенә һәм оештырылуына карата санитария-эпидемиология таләпләре»н раслау турында» карары, 15.05.2013, № 26.
Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Җитәкче, белгеч һәм хезмәткәр вазифаларының Бердәм квалификация белешмәлеген раслау турында» приказы («Мәгариф хезмәткәрләре вазифаларының квалификация сыйфатламалары» бүлеге), 14.08.2009, № 593.
Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Төп гомуми белем бирү программалары — мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» приказы, 30.08.2013, № 1014.
Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандартын раслау турында» приказы, 17.10.2013, № 1155.
Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү турында шартнамәнең үрнәк формасын раслау турында» приказы, 13.01.2014, № 8.
Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләүне уздыру тәртибен раслау турында» приказы, 07.04.2014, № 276.
Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча укытуга кабул итү тәртибен раслау турында» приказы, 08.04.2014, № 293.
Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирү Федераль дәүләт белем бирү стандартын кертүне оештыру мәсьәләләре буенча Координация төркеме турында» приказы, 22.05.2014, № 578.
Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Үрнәк төп белем бирү программаларын эшләү, аларга экспертиза уздыру һәм үрнәк төп белем бирү программалары реестрын алып бару тәртибен раслау турында» приказы, 28.05.2014, № 594.
Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балаларга өстәмә белем бирүне үстерү Концепциясен раслау турында» күрсәтмәсе, 04.09.2014.

### 1.2.Программаның максаты һәм бурычлары.

**Эш программасының максаты:**гаиләнә-тирә белән танышуда нигез буларак, яшь үзенчәлеге буенча бурычлар һәм проблемаларны чишү, башка балалар һәм өлкәннәр белән актив аралашу процессында балаларда культура тәҗрибәсе туплау, үзлексез белем алуга һәм мөстәкыйльлеккә әзерлек булдыру.

**Бурычлар:**

- милләтенең, теленең, социаль чыгышының нинди булуына карамастан, һәр балада аны яратуларына ышаныч, тормыш өчен уңайлы шартлар тудыру;
- шәхси һәм яшь һәм үзенчәлеге буенча балаларның һәрьяклы үсеше өчен уңайлы шартлар тудыру;
- балада социаль-әхлакый, физик, интеллектуаль, эстетик сыйфатлар үстерү;
- кеше эшчәнлегенең төп формаларында үзен-үзе ачу һәм иҗат итү сәләтен, ихтыяҗын формалаштыру, дөнья белән берлектә үзен-үзе танып белү, аның белән әңгәмә алып баруга әзерлек;
- баланың гомуми шәхси культурасын, шул исәптән сәламәт яшәү рәвешенең кыйммәтен, белем алу эшчәнлегендә алшартны, инициативасын, мөстәкыйльлеген һәм җаваплылыгын, актив тормыш позициясен формалаштыру;
- һәр баланың сәләтен һәм иҗади потенциалын үстерү;

- гуманлык кыйммәтләре һәм идеалы, ирекле кешенең хокуклары нигезендә баланың башка балалар, өлкәннәр һәм әйләнә-тирә белән үзара йогынтысын оештыру;
- балаларда Ватанга патриотик хис һәм мәхәббәт, рухи-әхлакый һәм социокультура кыйммәтләре нигезендә аның уңышлары өчен горурлану хисе тәрбияләү;
- шәхси һәм яшь үзенчәлеге, психо-физиологик үзенчәлекләр буенча социокультура мохите формалаштыру;
- гаиләнең һәм җәмгыятьнең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләре нигезендә гаиләнең һәм балалар бакчасының тәрбияви-сәламәтлек ресурсларын берләштерү;
- гаилә белән үзара партнерлык мөнәсәбәте урнаштыру, психологик һәм педагогик ярдәм күрсәтү, белем һәм тәрбия бирүдә ата-аналарның компетентлылыгын күтәрү;
- балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, максат, бурыч, алымнар, мәктәпкәчә белем бирү, башлангыч гомумбелем бирү дәрәҗәсендә күчүчәнлекне булдыру.

### 1.3. Программаны формалаштыруның принциплары.

Россиянең төп бердәм мәктәпкәчә белем бирү программасының ФДББСка яраклашуы түбәндәгеләрдә күренә:

- балачакның үзенчәлеге;
- кешелекнең гомуми үсешендә мәктәпкәчә чорның уникаль булуы;
- өлкәннәр һәм балаларның гуманлы аралашуы;
- баланың шәхесен хөрмәт итү;
- балаларның спецификасын исәпкә алып, белем бирү процессын уен, танып белү, эзләнү, иҗади активлык формасында тормышка ашыру.

Программаны тормышка ашыруның <u>төп принцибы</u>- яшь үзенчәлегенә туры килү. Мәктәпкәчә чорда ул уен, тәҗрибәләр ясау, проектлау, коллекция туплау, әңгәмә кору, проблемалы ситуацияләрне чишү һ.б.Әлеге эш төрләре мәҗбүри эшчәнлекне таләп итми, ә бәлки Программа балалар һәм педагогларның бердәм эшчәнлеге, шулайук балаларның мөстәкыйль эшчәнлекләре аша тормышка ашырыла.

<u>Интегральләштерү принцибы</u>-предметлы белем бирү программасын төзүгә альтернатив. Һәр белем бирү өлкәсендәге бурычлар башка өлкәләрне тормышка ашырганда да үтәлә ала.Тәкъдим ителгән белем бирү өлкәләре шартлы, ул материалны системалы оештыру өчен бирелгән.

<u>Проблемалы белем бирү принцибы</u> – билгеле бер авырлыкларны җиңү өчен бурычларны үтәү, сорауларга җавап эзләү. Бала өчен проблеманың практик мәгънәсе булу бик мөһим. Проблеманы чишеп, бала дөньяның күптөрле, үзгәрүчән булуын белә.

<u>Ситуатив принцибы</u> – белем бирү процессында балаларның кызыксынучанлыгын исәпкә алуга юнәлгән.

<u>Үсеш принцибы-</u> балаларның һәрьяклап үсешен тәэмин итү .

<u>Фәнни принцип</u>-юнәлешендә яңа технологияләрне, үрнәк тәҗрибәләрне киң куллану.

<u>Гаилә белән бердәм эшчәнлек принцибы</u>.Балалар бакчасында бала шәхесен формалаштыруда гаилә белән бердәм эшчәнлек. Балалар бакчасы һәм гаилә арасындагы элемтәне халык педагогикасына, алдынгы гаилә тәҗрибәсенә таянып ныгыту, милли рухта мәхәббәт тәрбияләүгә юнәлтү.

<u>Гендор яктан якын килү принцибы</u>.

<u>Балаларның бөтен эшчәнлектәдә</u> катнашуына этәргеч ясау принцибы.

<u>Сәламәтлекләре чикләнгән балаларның</u> үсеш үзенчәлекләрен исәпкә алу принцибы.(ОВЗ)

<u>Милли-региональ компонент принцибы.(ЭРС)</u>

<u>Комплекслы-тематик принцибы</u>.

<u>Тулылык, зарурлык һәм җитешлелек критерийларына туры килү принцибы</u> (җитәрлек күләмдә «минимум» материал кулланганда, куйган максатлар һәм бурычларны хәл итәргә мөмкинлек биреп).

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән эшләүнең төп формасы һәм алар эшчәнлегенең әйдәп баручы төре булып уен исәпләнә.

### 1.4. 5-6 яшьлек балаларның шәхси һәм яшь үзенчәлекләре

Мәктәпкәчә яшьтәге чор баланың шәхес булып формалашуында әһәмиятле роль уйный Алтынчы яшьтәге балалар үзен һәм башкаларны белергә омтыла, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтне аңлый башлый. Аларның сүзлекләрендә инде намуслылык, кайгыртучанлык, әдәплелек кебек сүзләр күбрәк урын ала. Балалар уенындагы мөнәсәбәтләр эчтәлек һәм интонация ягыннан алган рольгә туры килүче сөйләм белән үрелеп бара. Аларның реаль мөнәсәбәтләре вакытындагы сөйләм рольдәге сөйләмнән аерыла. Балалар социаль мөнәсәбәтләрне үзләштерә һәм олыларның төрле эшчәнлекләрендәге буйсынучанлык позициясен аңлый башлыйлар. Бер төрле рольләр аларны башкалары белән чагыштырганда күбрәк җәлеп итә.

Бу яшьтә сынлы сәнгать белән кызыксынучанлык аеруча көчәя. Алар бик еш рәсем ясый башлыйлар. Рәсемнәр эчтәлекләре ягыннан күп төрле: аларда уйлап чыгарылган ситуацияләр, тормыштан алган тәэсирләр, китапларга иллюстрацияләр чагылырга мөмкин. Рәсемнәр композиция чишелешенең оригинальлеге белән аерылырга, хәрәкәтсез, үсештәге мөнәсәбәтләрне чагылдырырга да мөмкин.

Конструкцияләү бу яшь өчен шартларны анализлый белүләре белән характерлана.Балалар агач конструктор детальләрен кулланалар һәм атыйлар. Булган материал белән корылманың детальләрен алыштыра алалар. Үрнәк төзелешне гомуми ысул белән тикшерә беләләр.Конструкцияләү эшчәнлегесхема нигезендә үзләре уйлап яки шарт буенча эшкә ашырыла.Күмәк эшчәнлек барышында конструкцияләү барлыкка килә.

Балалар берничә тапкыр бөкләп, кәгазьдән, шулай ук табигый материалдан конструкцияли алалар. Алар 2 ысулны үзләштерә: 1. Табигый материалдан сәнгати образ тудыру(бу очракта балалар табигый материалларны төрле детальләр белән тулыландырып, бербөтен образ тудыралар; 2.сәнгати образдан чыгып табигый материал табу (бу очракта бала образны тудыру өчен кирәкле табигый материал сайлый. Төсне, форма, зурлыкны. предметларның төзелешен аңлау, кабул итү формалаша.

Балаларның күзаллаулары системалаштырыла.Балалар төп төсләр һәм аларның төсмерләрен генә түгел, ә арадаш төсмерләрнең төсләрен дә, шулай ук турыпочмак, овал, өчпочмакларның формаларын да аералар. Бер дистә предметны зурлыклары буенча рәткә тезеп куя алалар.

Ләкин балалар объектныңпространстводагы урынын билгеләгәндә әгәр дә объектныңпространстводагы урыны туры килмәсә, авырыксынырга мөмкиннәр. Әгәр озынрак бормалы юлның башлангыч һәм соңгы нокталары арасындагы ара туры юлның башлангыч һәм соңгы нокталары арасындагы ераклыктан кыскарак булса да, балалар тарафыннан туры юл озынрак итеп кабул ителә.

Бу мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен кабул итү сәләтенең төрле ситуацияләрдә, бигрәк тә бер үк вакытта берничә капма-каршы билгеләрне истә тотарга кирәк булган очракта, аерым авырлыклар тудыруын күрсәтә.

Зурлар төркемендә образлы фикер йөртү үсеше дәвам итә. Балалар күрсәтмә планда биремне чишәргә генә түгел, хәтта объектны үзгәртергә, аның нинди эзлеклелектә бер-берсе белән бәйләнешкә керү мөмкинлеген күрсәтергә һ.б. да сәләтле. Ләкин болар бары тик балалар адекват фикерләү чараларын кулланган очракта гына дөрес булачак. Бу чаралар арасыннан күрсәтмә модельләштерү процессында туучы схемалаштырылган күзаллауларны, балаларның объект билгеләре системасы турындагы күзаллауларын чагылдыручы комплекслы күзаллаулар, шулай ук төрле объект һәм күренешләрнең үзгәрү стадиясен чагылдыручы күзаллаулар, ел фасылларының, көн белән төннең алышынуы, объектларның төрле йогынты нәтиҗәсендә зураюы һәм кечерәюе, үсеше турындагы күзаллауларны һ.б.атарга мөмкин. Моннан тыш, логик сөйләмле фикерләүнеңнигезе булган

гомумиләштерү сәләте камилләшә бара. Объектлар төркемнәргә үзгәрергә мөмкин булган билгеләре буенча берләштереләләр. Төркемнәрне логик берләштерү һәм тапкырлау операцияләре дә формалаша башлый.

Бу яшьтә уйлап чыгару сәләте үсү балаларга шактый оригиналь һәм эзлекле киңәйтелгән хикәяләр уйлап чыгарырга мөмкинлек бирә. Балаларның әлеге сәләте бары тик бу юнәлештә махсус эш алып барганда гына актив рәвештә үсәчәк.

Балаларның игътибар тотрыклылыгы үсә. Алар шулай ук игътибарларын кирәк юнәлешкә бора һәм башкага күчерә ала башлыйлар. Ирексез игътибардан аңлы игътибарга күчү күзәтелә.

Сөйләм, шул исәптән аның аваз ягы камилләшү дәвам итә. Балалар сызгырулы, чыңылдаулы һәм сонор авазларны дөрес әйтә башлыйлар. Шигырьләр укыганда, сюжетлы-рольле уеннар вакытында һәм көндәлек тормышта фонематик ишетү сәләте, сөйләмнең сәнгатьлелеге үсә, грамматик төзелеше камилләшә. Балалар барлык сүз төркемнәрен кулланалар, сүз уйлап чыгару белән актив шөгыльләнәләр. Сүз байлыклары арта. Синоним белән антонимнар актив кулланышка керә.Бәйләнешле сөйләм үсә. Балалар эчтәлекне дә, рәсемнәр буенча да иң мөһим генә түгел, ә детальләрне дә кертеп сөйли ала башлыйлар.

Бу яшьнең казанышлары түбәндәгеләр белән характерлана: уен эшчәнлегендә рольләр бүлешү; уен пространствосын төзи белү; югары нәтиҗәлелеге белән аерылып торган рәсем эшчәнлегенең алга таба үсеше; конструкцияләүдә үрнәкне карап гомумиләштерә белү. Зиһенгә алу объектларның катлаулы формаларын анализлау белән характерлана; фикерләү чараларын (схемалы, комплекслы күзаллаулар, циклы үзгәрешләр турында күзаллаулар) үзләштерү белән бергә фикер йөртү сәләте дә үсә, гомумиләштерү күнекмәләре, уйлап чыгару сәләте, тотрыклы игътибар, сөйләм, <u>*Мин*</u> образы үсә.

### 1.5. Программа үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре

Мәктәпкәчә балачакның үзгәлеге (бала үсешенең сыгылмалылыгы,аның үсеш вариантларының төрлелеге, аның табигыйлеге һәм нәрсәгә дә булса бәйле булуы) мәктәпкәчә яшьтәге баладан конкрет белем бирү нәтиҗәләренә ирешүне таләп итәргә мөмкинлек бирми һәм мәгариф программасын үзләштерү нәтиҗәләрен максат ориентирлары рәвешендә билгеләү зарурлыгын шарт итеп куя.

Мәктәпкәчә белем бирүнең ФДББСнда күрсәтелгән максат ориентирларын баланың ирешергә мөмкин булган казанышларының социаль-нормативсыйфатламалары буларак карарга кирәк. Бу — педагоглар һәм ата-аналарөчен өлкәннәрнең тәрбия эшчәнлегенең юнәлешен билгеләүче ориентир.

МББ ФДББСнда билгеләнгән максат ориентирлары Россия Федерациясенең бөтен мәгариф пространствосы өчен уртак булып тора.

Шулай итеп, «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасыориентирлары МББ ФДББСна һәм «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасына аңлатма язуында билгеләнгән максатларга һәм бурычларга нигезләнә, аларныңСтандартлар белән туры килгән өлеше МББ ФДББС текстлары буенча бирелә. «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасында, Стандарттагы кебек үк,максат ориентирлары кече яшьтәге балалар өчен (мәктәпкәчә яшькә күчүэтабында) һәм мәктәпкәчә яшьтәге зурлар төркемендәге балалар өчен (мәктәпкәчә белем бирүне төгәлләү этабында) тәгаенләнә.

#### 1.5.1 Максаториентирлары

• Бала төп мәдәни чараларны, эшчәнлек ысулларын үзләштерә, эшчәнлекнең төрле төрләрендә — уенда, аралашуда, танып белү-тикшеренү эшчәнлегендә, конструкцияләүдә һ.б да инициатива һәм мөстәкыйльлек күрсәтә; үзенә шөгыль төрен, уртак эшчәнлек буенча катнашучыларны сайлап алырга сәләтле.

• Бала дөньяга, хезмәтнең төрле төрләренә, башка кешеләргә һәм үз- үзенә карата уңай мөнәсәбәткә ия, аңа үзенең урынын белү хас; яшьтәшләре һәм зурлар белән актив аралаша, уртак уеннарда катнаша.

• Килешүләргә, башкаларның ихтыяҗлары һәм хисләре белән исәпләшергә, аларның уңышсызлыкларын бүлешергә һәм уңышларына сөенергә сәләтле, үз хисләрен, шул исәптән үзенә ышаныч хисен дөрес белдерә, каршылыкларны чишәргә тырыша. Төрле мәсьәләләр буенча үз позициясен аңлатырга һәм якларга сәләтле.

• Уртак эшчәнлектә хезмәттәшлеккә һәм лидерлык, һәм башкару функцияләрен дә үтәргә сәләтле.

• Барлык кешеләрнең дә, социаль чыгышлары, нинди этник төркемгә керүләренә, дини һәм башка инануларына, физик һәм психик үзенчәлекләренә карамастан, тигез икәнен аңлый.

• Башка кешеләргә карата эмпатиягә ия, мохтаҗларга ярдәмгә килергә әзер тора.

• Башкаларны тыңлый белә һәм башкаларның да үзен аңлауларына омтыла.

• Баланың хыялга бирелүе үсешкә ирешкән, ул эшчәнлекнең төрле төрләрендә, һәм барыннан да элек уенда, гамәлгә ашырыла; уенның төрле формаларын һәм төрләрен уйный белә, шартлы һәм чынбарлыктагы хәлләрне аера ала; төрле кагыйдәләрне һәм социаль нормаларны үтәргә сәләтле. Килеп туган төрле хәлләрне тотып ала һәм аларны дөрес бәяли белә.

• Бала сөйләм теленә шактый оста, үзенең уйларын һәм теләкләрен белдерә, сөйләмне үзенең уйларын, хисләрен һәм теләкләрен аңлату өчен, аралашу вакытында сөйләм тезмәләре төзү, сүзләрдә авазларны аерып карау өчен куллана ала, балада грамоталылыкның алшартлары формалаша.

• Балада эре һәм вак моторика үскән; ул хәрәкәтчән, түзем, төп хәрәкәтләрне ясый белә, үз хәрәкәтләрен тикшерә һәм алар белән идарә итә ала.

• Бала ихтыяр көчен җыярга сәләтле, эшчәнлекнең төрле төрләре вакытында социаль тәртип нормаларын һәм кагыйдәләрен үти ала, өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән мөнәсәбәтләрдә иминлекне саклау тәртибе кагыйдәләрен һәм шәхси гигиена күнекмәләрен үти ала.

• Башланган эш өчен җаваплылык сизә.

• Кызыксынучанлык күрсәтә, өлкәннәргә һәм яшьтәшләренә сораулар бирә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре белән кызыксына, табигать күренешләренә һәм кешеләр кылган гамәлләргә карата мөстәкыйль рәвештә аңлатмалар табарга тырыша; күзәтергә, экспериментлар ясарга һәвәс. Үзе турында, табигый һәм үзе яшәгән социаль дөнья турында башлангыч белемнәргә ия, балалар әдәбияты әсәрләре белән таныш, тере табигать, табигать белеме, математика, тарих һ.б. өлкәләр буенча элементар күзаллаулары бар; эшчәнлекнең төрле төрләре буенча, үзенең белем һәм күнекмәләренә таянып, карарлар кабул итүгә сәләтле.

• Яңалыкны кабул итәргә әзер, ягъни белем алуга, алга таба мәктәптә, институтта укуга карата уңай мотивациягә омтылыш күрсәтә.

• Тормышка (аның төрле формаларында) хөрмәт белән карый һәм әйләнә-тирә мохит турында кайгырта.

• Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгына, халык сәнгате һәм профессиональ сәнгать әсәрләренә (музыкага, биюгә, театраль эшчәнлеккә, рәссамлык эшчәнлегенә һ.б.ш.) эмоциональ бәя бирә.

• Патриотик хисләр кичерә, үз иле, аның казанышлары белән горурлана, аның географик төрлелеге, күпмилләтлелеге, иң мөһим тарихи вакыйгалары хакында күзаллаулары бар.

• Үзе, гаилә, традицион гендер юнәлешләрен дә эченә алган традицион гаилә кыйммәтләре хакында беренчел күзаллауларга ия, үз җенесенә һәм капма-каршы җенескә карата ихтирамлы.

• Гомуми кабул ителгән элементар нормаларны үти, «нәрсә яхшы, нәрсә начар» булуы турында беренчел күзаллауларга ия, яхшы гамәлләр кылырга омтыла; өлкәннәрне хөрмәт итә һәм кечкенәләр турында кайгырта.

• Сәламәт яшәү рәвеше турында башлангыч күзаллауларга ия. Сәламәт яшәү рәвешен кыйммәт буларак кабул итә.

### 1.5.2. Программаны үзләштерүнең нәтиҗәләрен бәяләү системасы

МББ ФДББС белән ярашлы рәвештә максат ориентирлары турыдан-туры, шул исәптән педагогик диагностика (мониторинг) рәвешендә дә, бәяләүгә алынмый һәм аларны балаларның реаль казанышлары белән формаль чагыштыру өчен нигез була алмый. Алар балаларның әзерлегенә һәм белем бирү эшчәнлегенә карата кабул ителгән таләпләргә туры килә торган объектив бәяләмәнең асылы булып тормый. Программаны үзләштерү арадаш аттестацияләр һәм тәрбияләнүчеләрнең йомгаклау аттестациясен уздыру белән кушылып китми. МББнең ФДББСннан күренгәнчә, максат ориентирлары идарә итү бу- рычларын хәл иткәндә турыдан-туры нигез була алмыйлар. Әлеге бурычларга түбәндәгеләр керә:

- педагогик кадрларны аттестацияләү;
- белем бирүнең сыйфатын бәяләү;
- балаларның соңгы, шулай ук арадаш үсеш дәрәҗәсен, шул исәптән мониторинг кысаларында бәяләү (шул исәптән күзәтүгә яисә балаларның нәтиҗәгә ирешүен тикшерүнең башка ысулларына нигезләнгән методлар кулланып тестлар уздыру формасында);
- максат ориентирларын биремне үтәүнең сыйфат күрсәткеченә кертү ярдәмендә муниципаль (дәүләт) биремнәренең башкарылуын бәяләү;
- оешма хезмәткәрләре хезмәтенә түләүнең стимуллаштыручы фондын билгеләү.

Әмма педагог үз эше барышында һәрбер баланың индивидуаль үсеш траекториясен булдырырга тиеш. Моның өчен педагогка үз эшен бәяләүнең балалар белән иң уңайлы рәвештә үзара бәйләнеш булдырырга ярдәм итүче инструментарие кирәк. Тәкъдим ителгән Программаны үзләштерү нәтиҗәләрен бәяләү системасында мәктәпкәчә белем бирүнең сыйфатын бәяләүне аңлауның үзгәрүе белән бәйле заманча тенденцияләр чагылыш таба. Беренче чиратта, игътибарны әкренләп объектив (тестлар уздыру) якын килүдән аутентик бәяләү ягына күчерү турында сүз бара. Тамырлары белән стандартлаштырылган тест традицияләренә китеп, объектив якын килү кысаларында тикшеренүләр махсус бурычларны хәл итү барышында балалардагы аерымлыкларны (еш кына җитешсезлекләрне) билгеләүгә юнәлтелгән иде. Әлеге тестлар килеп чыккан нәтиҗәләрне норма белән чагыштырырга мөмкинлек тудыра, шуның белән һәрбер баланың үз яшьтәшләре белән чагыштырганда үсеше турында мәгълүмат бирә. Шунлыктан мондый тестлар педагогик хәвефлелек төркеменә керергә тиешле балаларны ачыклауда киң кулланыла. Әлеге ысулның төп җитешсезлеге шунда: ясалма биремнәр еш кына балаларның көндәлек тормышыннан шактый ерак, шуңа күрә алар мәктәпкәчә яшьтәге балаларның реаль мөмкинлекләрен тулысынча чагылдыра алмыйлар. Тест ысулы балаларның социаль даирәсе үзенчәлекләрен исәпкә алмый, һәм аның нәтиҗәләренә корылган фаразлар да шактый шартлы. Аутентик бәяләүнең нигезендә түбәндәге принциплар ята. Беренчедән, асылда ул махсус биремнәрне үтәү нәтиҗәсенә түгел, баланың реаль тәртибен анализлауга карап корыла. Мәгълүмат турыдан-туры баланың тәртибен күзәтү ярдәмендә туплана. Күзәтү нәтиҗәләрен педагог гадәти тестларда куллана торган, мәктәпкәчә яшьтәге баланың реаль тормышына кагылышы аз булган уйлап чыгарылган ситуацияләрдә түгел, табигый мохиттә (уеннар вакытында, режим моментлары барышында, дәресләрдә) таба. Икенчедән, әгәр тестларны махсус өйрәтелгән профессиональ белгечләр (психологлар, медицина хезмәткәрләре һ.б.) уздырса, аутентик бәяне исә бала белән озак вакыт булган, аның тәртибен яхшы белгән өлкәннәр куя ала. Бу очракта педагог тәҗрибәсе бәяләп бетергесез. Өченчедән, аутентик бәя югары дәрәҗәдә структурлашкан. Ниһаять, әгәр тестлар ярдәмендә бәя кую очрагында ата-аналар алын- ган мәгълүматларның мәгънәсен һәрвакытта да аңлап бетермәсәләр һәм шуңа да еш кына балаларга тест уздыруга тискәре мөнәсәбәт күрсәтсәләр, аутентик бәяләү вакытында җаваплар аларга аңлаешлы. Ата- аналар теге яисә бу сорауга җавап эзләгәндә педагогның партнерлары булып китәргә мөмкин.

### 1.5.3. Педагогик диагностика

«Туганнан алып мәктәпкәчә» программасын гамәлгә ашыру балаларның индивидуаль үсешен бәяләүне күздә тота. Мондый бәяләү педагогик хезмәткәр тарафыннан педагогик диагностика (мәктәпкәчә яшьтәге балаларның индивидуаль үсешенә педагогик гамәлләрнең нәтиҗәлелеген бәяләү белән бәйле һәм аларны алга таба планлаштыруның нигезендә ятучы бәя бирү) кы- саларында уздырыла. Педагогик диагностика балаларның гадәти һәм махсус оештырылган эшчәнлектә активлыгын күзәтү барышында үткәрелә. Педагогик диагностика өчен инструментарий — балалар үсешен күзәтү карталары, алар һәрбер баланың индивидуаль динамикасын һәм үсеш перспективаларын түбәндәгеләр барышында билгеләргә мөмкинлек бирә:

• яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән аралашулар (контакт урнаштыру һәм аны дәвам итү, уртак карарлар кабул итү, каршылыкларны хәл итү, лидерлык һ.б. ысуллары ничек үзгәрә);
• уен эшчәнлеге;
• танып белү эшчәнлеге (балаларның сәләтләре, танып белү активлыгы үсеше ничек бара);
• проект эшчәнлеге (балаларның инициативалылыгы, җаваплылыгы һәм автономиясе үсеше ничек бара, үз эшчәнлеген планлаштыру һәм оештыру күнекмәсе ничек үсә);
• сәнгати эшчәнлек;
• физик эшчәнлек.

Педагогик диагностика нәтиҗәләре фәкать түбәндәге белем бирү бурычларын хәл итү өчен кулланыла ала:

1) белем бирүне индивидуальләштерү (шул исәптән балага булышлык күрсәтү, аның белем бирү траекториясен булдыру яисә аның үсеш үзенчәлекләренә профессиональ төзәтмә кертү);
2) балалар төркеме белән эшне оптимальләштерү.

Белем бирү эшчәнлеге барышында балаларның индивидуаль динамикасын бәяләү һәм үз гамәлләренә төзәтмә кертү өчен педагоглар диагностик ситуацияләр булдырырга тиеш.

# II.Эчтәлек бүлеге.

### 2.1.Баланың үсеше юнәлешләрендә белем бирү эшчәнлеге тасвирламасы

Баланың үсеше юнәлешләрендә белем бирү эшчәнлеге тасвирламасы биш белем өлкәләрендә күрсәтелгән.2-7 яшьлек балалар белән психолог-педагогик эшенең эчтәлеге белем бирү өлкәләре буенча: «Социаль-коммуникатив үсеш», «Танып-белү үсеше», «Сөйләм үсеше», «Сәнгати-эстетик үсеш », «Физик үсеш».

Психолог-педагогика эшенең эчтәлеге мәктәпкәчә яшьтәге балаларның индивидуаль һәм яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, төрле яклап үсешенә ориентлаша. Психолог-педагогика эшенең эчтәлеге балаларның физик, интеллектуаль, личностный сыйфатларын формалаштыру буенча мәҗбүри психологик сопровождение белән беррәттән, һәр белем бирү өлкәсенең үзенчәлеген чагылдыручы барлык белем бирү өлкәләрен үзләштерү барышында интегрированно хәл ителә. Шул ук вакытта программаның белем бирү бурычлары карары турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге кысаларында гына түгел, ә өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлеге, шулай ук мәктәпкәчә яшьтәге балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге белән режим моментларында да күздә тотыла Һәр белем бирү өлкәсе бүлеге башында блем бирү өлкәләренең максатларын һәм бурычларын билгеләүче ФГОС ДО цитатасы күрсәтелә.

Эшнең эчтәлеге мәктәпкәчә яшьтәге балаларның, аларның яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрен искә алып, төрле яклап үсешенә юнәлтелгән. Балаларның физик, интеллектуаль һәм шәхси сыйфатларын формалаштыру буенча пси- хологик-педагогик эш бурычлары белем бирүнең һәрбер өлкәсенең үзгәлеген чагылдыра торган бурычлар белән, мәҗбүри психологик тәэмин итү белән беррәттән, барлык белем бирү өлкәләрен үзләштерү барышында интеграцияле хәл ителә. Бу очракта программаның мәгариф бурычларын хәл итү турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге кысаларында гына түгел, режимлы моментлар

барышында да — өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлегендә дә, мәктәпкәчә яшьтәгеләрнең мөстәкыйль эшчәнлегендә дә карала.

**Социаль –коммуникатив үсеш өлкәсе**

5-6 яшьлек балаларның фикерләүләре үзенчәлекле булганга, баланың үз-үзен тотышында үзеннән-үзе көйләнү процессы өстенлек ала башлый, ирекле психик процессларның үсеше балаларның төрле өлкәдә тотрыклы оешуына китерә, хәрәкәтләрнең кагыйдәләргә буйсынуы төрле конфликтлы ситуацияләрнең килеп чыгуын булдырмый кала. Балаларның социаль культураның төрле төрләре турындагы белеме дифференцияле характер ала һәм алар продуктив , иҗади эшчәнлекнең төрле төрләрендә кулланыла.Программаны тормышка ашыру балалар белән эшчәнлекнең төрле ысулларын һәм алымнарын күздә тота (әкиятләрне сәхнәләштерү, әңгәмә, экскурсияләр, матур әдәбият уку, сюжетлы-рольле, дидактик уеннар, сөйләм, музыка тыңлау һ.б.), үзенчәлекле балалар эшчәнлегенең иң уңайлы яраклашуын фаразлый (коммуникатив, уен, танып белү, сөйләм, рәсем сәнгате, конструктив, музыка һ.б). <u>Мин-Кеше</u>: мин-малай, мин-кыз. Аларның охшашлыгы күп: уйнарга, җырларга, биергә, хайваннарны карарга, туганнарын, әти-әниләрен яраталар; төрле хисләр кичерәләр: моңсуланалар, шатланалар, елыйлар, сагыналар,дулкынланалар, ләкин төрлечә кичерәләр. Кешенең хисләрен йөзенә, тавышына, хәрәкәтләренә карап әйтеп була.Әгәр кешенең йөзе моңсу булса, тавышы акрын, җилкәләре төшкән, башы иелгән була, аңа начар, аңа булышырга: нәрсә булганын сорарга, кочакларга, сыйпарга, җылы сүзләр әйтергә, шәфкатьлелек күрсәтергә кирәк.Шәфкатьле кеше һәрвакыт башка кешенең авыртуын күрә, аңа ярдәмгә ашыга. <u>Малайлар һәм кызлар</u> бер-берсе, хайваннар, кечкенәләр, ата-аналар турында кайгырталар. Кызлар кайгыртучанлык, ягымлылык, яхшы күңеллелек күрсәткән чын хатын-кыз эшләрен бәяли. Малайлар - кыюлык, намуслылык, көч, вөҗданлылыкны. Вөҗданлы булу-ул үзеңнең нәселеңне данлау, аны бөртекләп яхшы эшләр белән тулыландыру. Малайларның һәм кызларның кызыксынулары төрлечә: малайлар шау-шулы уеннар, конструктор, чик сакчылары, янгын сүндерүчеләр булып уйныйлар, машина, танклар ясыйлар. Кызлар курчаклар, өйле уеннар уйныйлар, киенәләр; чәчәкләр, өйләр, кешеләр ясыйлар. Киресенчә дә булырга мөмкин. Ләкин бер-берсенең кызыксынучанлыгын хөрмәт итеп, комачауламый уйнарга кирәк.

<u>Ир-ат һәм хатын-кызлар</u> күбесенчә бер-берсенә охшаган: аралашырга, кунакка йөрергә, бүләк алырга яраталар. Хөрмәткә лаек ир-ат йомшак, зәгыйф кешене яклый, саклый, өлкәннәргә ярдәм итә, үз өстенә җаваплылыкны ала, намуслы, батыр, кыю. Хөрмәткә лаеклы хатын-кыз һәрвакыт ачык йөзле, кайгыртучан, аның янында тыныч, җылы, рәхәт була, ул тәмле ашата, назлый, тынычландыра, тәртип булдыра ала. Түземлелек, тырышлык, җентекләп эшләүне таләп итүне хатын-кыз башкара.

<u>Минем гаиләм.</u>Гаилә якын һәм ерак туганнардан тора. Якын туганнар – әти, әни, әби, бабай, апа, абый, эне, сеңел. Ерак туганнар-әти-әнинең абый-апалары. Һәр гаиләдә “хатын-кызлар”, “ир-атлар” бәйрәме үткәрелә. Гаиләдә ир-атлар һәм хатын-кызларны төрлечә атыйлар. Малай гаиләдә –ул, абый, эне, онык; кыз – кыз бала, апа, сеңел, онык; ир-ат – әти, ул, ир; хатын-кыз –әни, кыз, хатын. Гаиләдә иң хөрмәтле кешеләр – әби, бабай, алар турында кайгырталар, аларны саклыйлар.

<u>Балалар бакчасы.</u> Балалар бакчасы һәркемгә кадерле. Анда эшләүчеләр балаларга әйбәт булсын дип кайгырталар: пешекче, тәрбияче ярдәмчесе,ишек алды җыештыручы, тәрбияче, өлкән тәрбияче, кер юучы, шофер, мөдир. Бакчада эшләүче өлкәннәр балаларга яхшы булсын өчен күп эшлиләр: үсемлекләр турында кайгырталар, веранда буйыйлар, кар төзелешләр ясыйлар. Балалар аларга хөрмәт белән карыйлар: исеме, әтисенең исеме белән дәшәләр, елмаялар, бәйрәмнәр белән котлыйлар, бүләкләр бирәләр.

Кешенең килеп чыгуы һәм үсеше. Һәр кешенең үз тарихы бар. Кешенең тарихы ул туганнан соң башлана. Ул туган вакытны туган көн дип атыйлар. Бала бераз үсә төшкәч, бакчага бара, күп нәрсәгә өйрәнә, дуслар таба. Бакчадан соң мәктәпкә бара, бала дөнья, тормыш турында күп нәрсәгә өйрәнә, үзе эшли. Мәктәпне тәмамлагач, алга таба укырга керә яки эшли башлый. Зур кеше булгач,гаилә кора, балалар үстерә. Картайгач, пенсиягә китә, өйдә ял итә, сәяхәткә китә. Өлкән кешеләр күп беләләр, тормыш тәҗрибәсе туплыйлар. Аларга булышырга кирәк.

Гаилә тарихы. Һәр кешенең исеме бар, исем ул тугач бирелә. Исемнәр төрле була, алар нәрсә дә булса аңлата.Кеше үз исемен ярата. Өлкән кешеләрне исеме, әтисенең исеме белән атыйлар, ул хөрмәт итү дигәнне аңлата.Кешенең фамилиясе бар, гаиләдә фамилия бертөрле була. Гаиләнең намусын сакларга кирәк: ялганламаска, хәлдән килмәгәнгә сүз бирмәскә, ата-аналарны картайган көндә ялгыз калдырмаска кирәк.

Туган шәһәр. Һәр шәһәрнең тарихы була, яңа, иске, борынгы шәһәрләр бар.Борынгы шәһәрләр кешегә яшәү өчен җайлы урында барлыкка килгән: яңа шәһәрләр файдалы казылмалар(нефть, күмер) булган җирдә, ял итә торган урыннарда (диңгез, күл) Һәр шәһәрнең туган көнен, тарихын билгели торган күп кенә башка даталары бар. Һәр шәһәрдә дә музей, һәйкәлләр, урамнар, аларның үз исемнәре, тарихы бар: алар күренекле кешеләр исемнәре белән атала.

Туган ил. Туган илнең дә үз тарихы бар.Илебезнең исеме-Россия-Рәсәй. Россия Федерациясе –зур, күпмилләтле дәүләт. “Русь” сүзе якты мәгънәсен аңлата. Кеше кайда туса, аның туган җире, иле шунда була. Ватанны сакларга, якларга әзер тору, аның белән горурлану – ул кешедә була торган иң яхшы нәрсә. Ватанны яраткан кеше ата-анасын, туганнарын, шәһәрен, урамын, балалар бакчасын ярата.

Татар милли культурасы. Йорт төзелешләре яшәр өчен төзелгән. Татарлар йорт хайваннары асраганнар, игенчелек белән шөгыльләнгәннәр. Бөтен төр хезмәтләр дә бер-берсенә бәйле булган: тегермәнче-игенчегә, балта остасы-агач кисүчегә, терлекче-тимерчегә.Шуңа кешеләр дус, тату яшәгәннәр, шул турыда әкиятләр, җырлар, мәкальләр уйлап чыгарганнар. Табигать кешеләрне туендырган, җылы биргән, киендергән, дәвалаган. Кешеләр әйләнә-тирәгә булган мөнәсәбәтләрен әкиятләрдә, җырларда чагылдырганнар. Аларда намуслы яшәү, бер-береңә авыр вакытта булышу, өлкәннәрне, ата-аналарны хөрмәтләү, туган илне ярату сурәтләнгән.

Сюжетлы-рольле уеннар. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның тормышында сюжетлы-рольле уеннар аерым урын алып тора. Педагог балаларны уен сюжетын үстерергә өйрәтә, башкаручылар арасындагы мөнәсәбәтне ныгыта, таныш уен сюжетларын берләштерә, шуларның берсен төп сюжет итеп алырга һәм балаларга рольләр тәкъдим итә, кара-каршы сөйләмне формалаштыруны, рольләрне башкаручыларның эш-хәрәкәтен планлаштыруны дәвам итә. Педагог уен барышында туган традицион һәм заманча мөстәкыйльуен эшчәнлеген хуплый: “Кафе”, “Коткаручылар хезмәте”, “Музей”, “Дача” “Күргәзмәләр залы”, “Алтын эзләүчеләр” һ.б.

Эксперимент уеннар – бу яшьтәге балалар өчен әһәмиятле урын тота. Алар балага югары дәрәҗәдәге мөстәкыйльлек кенә биреп калмыйлар, ә үз-үзләрен ачарга мөмкинлек бирәләр.

Театр уеннары. Зурлар төркемендә сәхнәләштерелгән уеннар балаларның мөстәкыйльлеген үстерә, курчак спектакльләре, сәхнәләштерелгән уеннарның барышын күзәтүне формалаштыра.Тәрбияче балаларны персонажларның төрле хәрәкәтләрен күрсәтергә генә өйрәтеп калмый, ә геройларның эмоциональ халәтен күрсәтү сәләтен дә үстерә (мимка, поза). Педагог курчакларны йөртү (бибабо, өстәл курчаклары һ.б.) белән таныштыра, хәрәкәтләрне җыр белән башкара.Балалар рольләрне башкарганда костюм элементлары куллану аларга үзләрен теге яки бу образда итеп хис итү өчен әһәмиятле. Образга кереп уйнаганда балада иҗади мөстәкыйльлек, нәфасәти зәвык тәрбияләнә.

Режиссер уеннары. Зурлар төркемендә режиссер уеннары әкренләп катлаулана һәм төрләнә бара: катнашучылар күбәя, аларның үзара бәйләнеше дә катлаулана, төп һәм уртача геройлар билгеләнә.

**Коммуникатив сәләт үсеше**. Ситуацияне исәпкә алып аралашу, әңгәмәдәшенә ориентлашу коммуникатив сәләт үсешенең әһәмиятле шарты булып тора. Бала өлкәннәр инициативасы белән туган әңгәмә темасын дәвам итә, сорауларга җавап бирә, кире кага ала. Балаларда сөйләм культурасын үстерү мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында гына түгел, ситуациягә карап сөйләм этикетың төрле формаларын һәм кагыйдәләрен күзаллауны формалаштыру нигезендә гаиләдә дә әһәмиятле: ата-аналар балалар белән бергәләп хикәяләр уйлап чыгара, аларның рәсемнәрен ясый, әдәби әсәрләрне укыганнан соң әңгәмә алып баралар. Балаларны вербаль булмаган аралашу чараларын(мимика, жест),төрле интонацияләр кулланырга, сөйләмнең темпын һәм тавыш көчен сакларга өйрәтү әһәмиятле.

**Куркынычсызлык куьтурасын формалаштыру**. Безнең төркемендә турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге белем бирү ситуациясе формасында тормышка ашырыла, аның барышында балалар әйләнә-тирәнең төрле аспектлары белән танышалар, билгеле бер вакыйгага анализ ясарга, куркынычсызлык кагыйдәләренең асылына төшенергә, аларны мөстәкыйль формалаштырырга өйрәнәләр. Төп басым балаларны төрле төр эшчәнлекнең культуралы һәм куркынычсыз башкарылган моделе белән таныштыруга ясала. Белем бирү структурасы психик процессларныңүсешенә ярдәм итә. Белем бирү ситуациясе зурлар төркемендә турыдан-туры белем бирү эшчәнлеген оештыруның төрле формадагы компоненты булырга мөмкин: эзләнү, практик-ориентлашу, иҗади проектлар, сюжетлы-рольле уеннарга алдан әзерлек, практикумнар, иҗади мастерскойлар, шөгыльләр. Турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге вакытында алган күзаллаулар һәм тәҗрибәләр режим моментларында үткәрелгән белем бирү эшчәнлегендә тормышка ашырыла. Иртән килгән балалар белән куркынычсызлык кагыйдәләре турында белемне актуальләштерергә ярдәм итүче әңгәмәләр үткәрелә, хезмәт вазифаларын, гигиена процедураларын башкарганда, уен эшчәнлеге барышында куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәүгә игътибар бирелә. Саф һавада максатчан йөргәндә,хәрәкәтле уеннар уйнаганда, хезмәт эшчәнлеге вакытындакуркынычсызлык кагыйдәләре саклана. Матур әдәбият белән танышканда, музыка әсәрләре тыңлаганда, сынлы сәнгатьтә, яраткан әкиятләрне сәхнәләштергәндә, мультфильмнар, видеофильмнар караганда, иҗади эшләрдә куркынычсызлык культурасы образлы күзаллаулар формасында тирәнәйтелә. “Физик үсеш”үстерешле

өлкәсе балаларга үз сәламәтлегенә аңлы караш тәрбияли. Программа гаиләдә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәүгә игътибар бирә. Мәсәлән, “Таныш булмаган кешеләр белән аралашканда куркынычсызлык” бүлегендә педагоглар балаларны матур әдәбият әсәрләре белән таныштырып, ситуацияне анализлый, персонажларның үз-үзен тотышын бәяли, алынган мәгълүматларны сюжетлы-рольле, режиссер уеннарына кертә. Ата-ана үрнәк бып тора. Гаилә, ата-ананың төп бурычы-куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәүне игътибар үзәгендә тоту.

Табигать һәм куркынычсызлык. Танып белү өлкәсендә алган белемнәр нигезендә балаларда төрле үсемлекләр, гөмбәләр белән килеп чыккан ситуацияләр нәтиҗәсендә балаларның табигатьтә үз-үзләреннең тотышлары турында күзаллау фомалаша. Матур әдәбият белән танышканда , күзәтүләр нәтиҗәсендә, продуктив эшчәнлектә балаларда үсемлекләргә, аеруча куркынычлы хайваннарга (елан, талпан), гөмбәләргә сак караш тәрбияләнә. Табигатьтә була торган хәвефле ситуацияләрдән саклану, аларны булдырмау чаралары өйрәнелә.

Урамда куркынычсызлык. “Гаилә”, “Светофор”, “Машина йөртүчеләр” сюжетлы-рольле уеннарын, режиссер, дидактик уеннар уйнаганда, матур әдәбият әсәрләре укыганда, экскурсияләр, күзәтүләр үткәргәндә, мультфильмнар, телетапшырулар

караганда балаларда шәһәр урамнары төзелеше, юл хәрәкәте, машиналар турында күзаллау формалаша, алар юл хәрәкәте кагыйдәләре белән танышалар.

Өйдә куркынычсызлык. Педагог балаларны өйдә куркынычсызлык кагыйдәләре белән таныштыра, үзеңнең өй адресыңны белүнең әһәмиятен ачыклый, проблемалы ситуацияләрдә үзеңне ничек тотарга кирәклегенә өйрәтә.

**Хезмәт. Өлкәннәр хезмәте белән таныштыру**. Педагог балаларны төрле һөнәр ияләренең хезмәте белән таныштыра. Һәр баланының үз гаилә әгъзаларының һөнәрләре турында сөйләвен, берничә һөнәр турында сөйли һәм күзаллый белүен хуплый. Һәрбер һөнәр иясенең хезмәт нәтиҗәсенә хөрмәт белән карарга өйрәтә, һәр хезмәт эшчәнлеге арасындагы бәйләнешне күрергә ярдәм итә.

**Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү**.Педагог балаларга культура-гигиена күнекмәләре бирә, мөстәкыйльлекне мактый һәм нәтиҗәне бәяли. Балаларның культура эшчәнлегенә : чиста ашау, тавышсыз эчү, чәнечке-пычак куллану, салфеткадан файдалану һ.б. игътибар бирә.

Хуҗалык-көнкүреш хезмәте – балаларның төркем, аш бүлмәсендәге, мәйданчыктагы хезмәтләрен хуплый, эшчәнлекләрдән соң эш урынын җыештырырга өйрәтә.

Табигатьтәге хезмәт. Педагог балаларны табигать объектларын карарга тарта. Шул ук вакытта тере объектларның экологик, биологик, географик үзенчәлеген исәпкә алып аларга сак карарга, табигать почмагында дежурлык вазыйфаларын дөрес үтәргә,эш коралларын чиста тотарга, җәй көне бакча эшләренә, ташландык әйберләрдән уенчыклар ясарга өйрәтә.

## Танып белү үсеш өлкәсе

**Әйләнә-тирә белән танышу**. Балалар глобус,географик карта, йолдызлар картасын карыйлар. Галәм, аны кешенең үзләштерүе турында беләләр.Ай исемнәре һәм аларны эзлеклелеге турында календарь буенча танышалар. Балаларның вакыт турында, әби-бабайларның бәләкәй чакларын, кешеләрнең тау куышлыгында яшәгән вакытларын һ.б. беләселәре килә. Балалар табигатьне, сезонлы күренешләрне күзәтәләр, календарьда билгеләп баралар. Өс, баш, аяк киемнәре, аларның сезонлы үзенчәлекләре, төрле һөнәрләр өчен махсус киемнәр турында мәгълүмат алалар. Тәрбияче теге яки бу махсус киемнең ни өчен төрле һөнәр иясенә бары тик шул кием генә кирәк булуын балаларның үзләреннән әйттерергә омтыла.Балалар кайбер материалларның нәрсәдән ясалуын, аның өчен нәрсә кирәк булуын беләләр. Ерактарак булган кызыклы урыннар: цирк, курчак театры, аэропорт, диңгез порты, заповедник һ.б. белән танышалар. Төрле спорт ярышлары үткәргән вакытта балалар олимпиада, спорт төрләре турында беләләр.Тәрбияче балаларны почта, башка аралашу-мәгълүмати чаралар, хатлар белән таныштыра. Балалар бакчасындагы агачлар, куаклар, гөмбәләр, бөҗәкләр,кошлар белән күзәтүләр үткәрәләр. Үз тирәлегенең сулары, анда яшәүче җан ияләре белән танышалар.Тәрбияче балаларга табигатьтә һәрбер җан иясенең кирәклеге турында сөйли. Ташлар, ком, балчык, төрле ландшафтлар белән таныштыруны дәвам итә.

**Танып белү-эзләнү эшчәнлеге**.Тәрбияче предметларның үзлеген аерып күрсәтергә өйрәтә(көпшәк, каты, бөгелүчән, ныклы,уалучанһ.б.). Предметның яңа үзлекләре белән таныштыруны оештыра, төрле материалларны(кәгазь, картон,тукыма) танырга, сүзләр белән атарга(пластмасс,йон, мех һ.б.)өйрәтә. Кәгазьнең ничек ясалуын, аны файдалы куллану; төрле материалны ясаганда әйләнә-тирәнең ничек пычрануын, чүп-чарның ничек килеп чыгуын һәм кая китүен, аларның кире эшкәртелүен сөйли. Сыеклыкның агуын, таралучан әйберләрне салырга кирәклеген аңлата. Балалар тере һәм тере булмаган объектларны чагыштырырга, аларның бәйләнешләрен аңларга өйрәнәләр. Тәрбияче балаларны бакчаның планы, экологик сукмак, шартлы билгеләр белән таныштыра, күзәтүләр, тәҗрибәләр өчен шартлар тудыра: мини-лабораториядә табигый байлыклар, ясалма һәм ташландык материаллардан тәҗрибәләр өчен эш кораллары ясыйлар. Балалар үзлектән гипотеза төзиләр, нәтиҗәне чагыштыралар.

**Иң гади математик күзаллауны формалаштыру**. Зурлар төркемендә эшчәнлекнең әкренләп гамәлнең предмет белән модельдән математик график модельгә күчүе яңа караш булып тора.Шул максаттан чыгып, эш дәфтәрләре кулланыла башлый, балаларга мөстәкыйль проблемалы ситуация бирелә. Предметларны чагыштыру. Балалар предметларны үзенчәлекләре буенча төркемнәргә аералар, бөтен һәм өлеш арасындабәйлелекне, артык предметны табалар; пердметларның төс, форма, зурлыгын символлар белән билгелиләр; төркемдәге предметлар тигез түгеллеген билгеләр белән язалар, 10 га кадәр саныйлар. Саннар предметлар белән дә, график юл белән дә билгеләнә, кушу һәм алу арифметик гамәлләре формалаша башлый.

Зурлык. Зурлар төркемендә предметлар шартлы билге белән үлчәнә. Балалар төрле киңлектәге,биеклектәге, озынлыктагы предметларны үсә яки кими бару тәртибендә урнаштырырга, урнашу тәртибен белергә, үлчәмнәре буенча чагыштырырга өйрәнәләр. Чагыштыру өчен алынган предметларның берсенең шартлы үлчәме ярдәмендә ике предметны зурлыклары(озынлыгы, киңлеге, биеклеге) буенча чагыштырырга өйрәнәләр. Предметларның зурлыгын (озынрак-кыскарак, биегрәк-тәбәнәгрәк, киңрәк-таррак) күз күләме белән билгеләргә өйрәнәләр.

Форма.түгәрәк һәм турыпочмаклыкны чагыштыру нигезендә , балаларны овал белән таныштыру. Дүртпочмак турында аңлату: квадрат һәм турыпочмаклыкныңдүртпочмак төрләре икәнлегенә төшендерү. Формалары буенча таныш предметларны чагыштыру, якын тирәдә бертөрле һәм төрле формалы предметларны танып белергә өйрәтү(китап, картина, өстәл- турыпочмаклы һ.б.)

Тирә-юньдә һәм вакытта ориентлашу. Алтынчы яшьтәге балалар тирә-юньдә ориентлашуны үзләштерә башлыйлар (сулда, уңда, аста, өстә, алда, алдында, артында, арасында, янәшә). Үзенең яки башка предметның торышына карап, теге яки бу предметның урынын билгеләү. Бирелгән юнәлештә хәрәкәт итә белү, сигнал буенча һәм маршрут күрсәткечләренә (уклар) карап үз торышыңны билгеләү; әйләнә-тирәдәге предметларга карап үз торышыңны билгеләү. Балаларны кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтү(сулда, уңда, аста, өстә). Иртә, көндез, кич, төннең тулы бер тәүлек тәшкил итүе турында күзаллау бирү. Атна көннәрен эзлекле рәвештә исемнәре белән атап чыгарга, бүген нинди көн, кичә нинди көн иде, иртәгә нинди көн икәнен әйтергә өйрәтү.

**Конструкцияләү.**Саф һавада булганда, экскурсияләр вакытында педагог балаларны дизайн иҗатының төрле төрләре (архитектура, интерьер, автомобиль, җиһазлар, уенчыклар һ.) белән таныштыра.Балалар төзегән корылмлар, конструкцияләр һәм әйләнә-тирәләрендә күрә торган корылмалар (өйләр, ишегалды һ.б.) арасында бәйләнеш урнаштыра белергә, конструкцияләрнең төп өлешен һәм характерлы детальләрен күрсәтә белергә өйрәтә.Балаларда күмәк эшләү, эшләрен уртак ниятләре белән яраштырып берләштерү күнекмәләрен бирә, мөстәкыйльлекне, иҗадилыкны хуплый. Балаларның үсеше түбәндәге конструктив эшчәнлек чаралары ярдәмендә бара: 1. Тәҗрибәләрне туплау һәм гомумиләштерү өчен иң уңайлы шартлар тудыру. 2.Үзләштерелгән алымнарның төрле ситуацияләргә инициативалы күчеше. 3. Мөстәкыйль эшчәнлектә ирекле алымнар куллану (конструктив, уен, сәнгать). 4.Уен һәм күнегүләрдә шартлы уенчыклар куллану. 5. Практик эшчәнлекнең эчке планга (фикерләү, күзаллау) күчүе, фикерләүнең үзгәрүе, нәтиҗәне фаразлау һәм иң гади мәсьәләләрне чишү– форма һәм конструкция белән күңелдән тәҗрибә ясау ул.

## Сөйләм үстерү үсеш өлкәсе.

**Авазларны дөрес әйтергә өйрәтү**.Авазларны дөрес, ачык итеп әйтергә, сүзләрне үз мәгънәсендә кулланырга өйрәтү эшен дәвам итү. Әйтелеше һәм яңгырашы буенча охшаш тартык авазларны ишетеп аера һәм ачык итеп әйтә белү күнекмәләре бирү: с-з, с-ц, ш-щ, ч-ц, с-ш, ж-з, л-р; сызгырулы, чыжылдаулы, сонор, калын һәм нечкә авазларны аерырга өйрәнү. Фонематик ишетү сәләтләренүстерү. Сүздә авазның урынын билгеләргә

(башында, уртасында, ахырында) өйрәтү. Сәнгатьле сөйләм өстендә эшләү.

**Сүз байлыгын үстерү.**Тирә-юнь турындагы белемнәрен киңәйтү исәбенә, балаларның сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру.Көнкүреш предметларын белдерүче, өлкәннәрнең һөнәрләрен аңлатучы, үсемлекләр һәм хайваннар, кошлар, табигать күренешләре атамалары; предметларның төрле билгеләрен(төсен, формасын h.б.), кешеләрнең характерын белдерүче сыйфатлар; кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен, хезмәткә карата мөнәсәбәтләрен, кәефләрен h.б. белдерүче рәвешләр; кешенең эш-гамәлләрен, хезмәт эшчәнлеген белдерә торган фигыльләр исәбенә балаларның сүзлеген баету, кулланышка кертү. Исемнәрне сыйфатлар белән бәйләргә өйрәтү (ак-кар, шикәр; матур-күлмәк, чәчәк), куллану күнекмәләрен бирү.

**Сөйләмнең грамматик төзелеше**. Җөмләдә сүзләрне яраштыра белү күнекмәләре бирү эшен дәвам итү: исемнәрне саннар белән, сыйфатларны исемнәр белән яраштырып сөйләргә өйрәтү. Сүздә дөрес куелмаган басымны, тартык авазларны чиратлаштырудагы хаталарны әйтә белергә өйрәтү. Сөйләшкәндә, хикәяләр сөйләгәндә, әңгәмәләрдә сүз ясагыч кушымчалардан файдаланырга өйрәтү: авылдаш. ташсыз h.б. Тамырдаш сүзләр ясау күнекмәләре бирү: бал баллы. Берлек сандагы сүзләрне күплек формасына әйләндерә белергә өйрәтү эшен дәвам итү. Боерык фигыль ясый белү күнекмәләре бирү. Сөйләмдә гади кушма җөмләләрне куллану күнекмәләрен ныгыту.

**Бәйләнешле сөйләм**. Балаларның монологикһәм диалогик сөйләмен үстерү юнәлешендә эшләү: иптәшләре белән тыныч, ягымлы итеп сөйләшә белергә, башкалар сөйләгәнне игътибар белән тыңларга өйрәтү. Сораулар бирергә, тәрбияче һәм балалар биргән сорауларга төгәл җавап бирергә күнектерү. Күләме зур булмаган әкият, хикәяләрне тәрбияче сорауларыннан башка, бәйләнешле, эзлекле итеп сөйләүкүнекмәләре бирү. Балаларны, билгеле бер әйбер турында яки рәсемнәргә карап, тәрбияче үрнәгендә яки бирелгән план нигезендәкечкенә хикәяләр төзеп сөйләргә өйрәтү. Үз тәҗрибәңнән чыгып сөйләргә өйрәтү дәвам ителә.

***Русский язык****.Задачи обучения русскому языку детей 5-6 лет* ***(УМК)*** формирование, развитие умений и навыков аудирования, говорения в игровых ситуациях по темам “Игры и игрушки” “Дом, в котором я живу”, “Посуда и продукты питания”, “Сад и огород”, “Транспорт”, “Одежда и обувь”, “Домашние и дикие животные”. Обогащение активного словарного запаса существительными, прилагательными, глаголами, наречиями, местоимениями, числительными; формирование умений согласовать части речи. Выработка умений и навыков понимать смысл предложений с вопросительнымизнаками. Различать значения предлогов в, на. Выработка умений и навыков вести диалог, составлять рассказы, описания. Разучивание стихотворений, песен, считалок на русском языке.

## Нәфасәти үсеш өлкәсе.

**“Матур әдәбият һәм фольклор” юнәлеше**. Зурлар төркемендә матур әдәбиятны кабул итү укылган әсәрнең мәгънәсен аңлау, бәя бирү белән бара. Балалар геройларга карата үзләренең эмоциональ карашларын аңлый, әсәрне жанр буенча аера, чагыштыра, әдәби телнең кайбер сәнгатьле чараларын күрә белә башлыйлар. Бу яшьтә образлы күзаллау геройларның тышкы кыяфәтен күз алдына китерү, әсәрнең ахырын уйлап чыгарып сөйләү сәләте үсә. Фольклор әсәрләренең спектры киңәя: санамышлар, мәкаль, әйтемнәр өстәлә. Иҗади эшләр белем бирү процессының аерылгысыз юлдашы- педагог балаларны уйлап чыгару процессына җәлеп итә, мактый. Еш кына әсәрләр темалар буенча берләштерелә. Бу бер үк әсәрнең төрле автор тарафыннан төрлечә кабул ителүенә ярдәм итә. Шигырьләрне яттан сәнгатьле итеп сөйләү күнекмәләре бирелә.Текстны рольләргә бүлеп уку, әсәрләрне сәхнәләштерү күнекмәләре булдыруга булышлык итә. Китаплар белән таныштыру эше дәвам итә.

**“Продуктив сәнгать эшчәнлеге”**. Блаларның *сынлы сәнгать* белән кызыксынуларын үстерү өстендә эшләү. Кабул итү органнары эшчәнлеген (күрү, ишетү, тою) үстереп,

балаларның сенсорик тәҗрибәсен баету. Нәфасәти кабул итү сәләтен үстерү. Предмет һәм күренешләрне күзәткәндә, фикерләү операцияләрен (анализ, чагыштыру, охшату, аермаларын табу, гомумиләштерү) үстерү. Сурәтләрдә предметларның төп билгеләрен (форма, зурлык, төс) генә түгел, бәлки характерлы детальләрн, кисәкләрнең чагыштырма зурлыкларын, биеклекләрен, бер-берсенә карата урнашу тәртибен күрсәтергә өйрәтү.

Сурәтли белү күнекмәләрен камилләштерү, иҗади сәләтне формалаштыру. Форма, төс, пропорцияләрне тоемлау.

*Халык декоратив-гамәли сәнгате* (Городец, Гжель, Полхов-Майдан һ.б.) белән танышыуны дәвам итү, халык уенчыклары турында күзаллауны киңәйтү. Балаларның декоратив иҗатын үстерү. Балаларны *сюжетлы композицияләр* тудырырга, сурәтләрне кәгазь битенең аскы өлешендә бер сызыкка урнаштырырга өйрәтү.Сюжеттагы төрле предмет һәм объектларны зурлыклары буенча чагыштырырга, бер-берсен каплый торган предметларны рәсемдә дөрес урнаштырырга өйрәтүне дәвам итү.

Балаларны төрле материаллардан *әвәләүнең* үзенчәлекләре белән таныштыруны дәвам итү. Натурадан карап, күзаллап таныш предметларны әвәләп ясау күнекмәләрен үстерү, характерлы үзенчәлекләрен, кисәкләрне пропорцияләре һәм детальләр зурлыгындагы аерымлыкларны чагылдыра белүләренә ирешү. Әвәләгәндә образның мәгънәлелеген чагылдырырга, кеше һәм хайван сыннарын хәрәкәттә әвәләргә, зур булмаган предмет төркемнәрен гади сюжетка берләштерергә өйрәтү. *Декоратив әвәләү*үзенчәлекләре белән таныштыруны дәвам итү. Халык уенчыгы тибында Дымково, Филимоново, Каргопольск уенчыкларын әвәләргә өйрәтү.

*Кисеп ябыштыру*. Кәгазьне кыска һәм озын тасма итеп кисеп, квадратлардан түгәрәкләр, турыпочмаклыктан овал кисеп, һ.б.сурәтләр барлыкка китерү. Берничә тапкыр бөкләгән кәгазьдән бертөрле фигуралар, икегә бөкләгән кәгазьдән-симметрияле сурәтләр кисәргә өйрәтү. Предметлы һәм сюжетлы композицияләр барлыкка китерү.

**Музыка тәрбиясе.**Балаларны композиторлар турында кыскача белешмәләр, классик, халыкчан һәм заманча музыкаль әсәрләр белән таныштырып, музыкага мәхәббәт тәрбияләү, кызыксыну хисләрен, нәфасәти тойгыларын үстерүне дәвам итү.Музыкаль сәләтләрен (музыканы ишетү, хәтер, ритм тойгысы, тембрларны аеру), музыкага карата мөнәсәбәтләрен үстерүне дәвам итү.

Музыка әсәренең жанр төрләрен (марш, бию, җыр) аера белергә өйрәтү, музыкаль хәтерләрен камилләштерү. Җыр күнекмәләрен формалаштыруҖырларны музыка уен коралларына кушылып яисә мөстәкыйль рәвештә ялгыз башкара алу сәләтен үстерү, җыр белән кызыксынуларын, җырлау теләкләрен үстерү.

**Физик культура үсеш өлкәсе**

**Физик культура һәм сәламәтләндерү эшләре.** Балаларның сәламәтлеген ныгыту өстендә эшләүне дәвам итү: организмны чыныктыру, төп хәрәкәтләрне камилләштерү, гәүдәне төз тоту гадәтен ныгыту. Мөстәкыйль рәвештә хәрәкәтле, спорт уеннары оештырырга, физик күнегүләр башкарырга, йөзәргә һәм гидроаэробика элементларын өйрәтү. Гимнастика эскәмисенең тар рейкасы һәм бау буенча атлап, баш өстенә ком тутырылган кечкенә капчык куеп тигезлекне саклау күнегүләре ясау. Гадәти йөгерү, аяк очларында тезләрне югары күтәреп каршылыкларны җиңеп йөгерү, шуышу, үрмәләүне камилләштерү. Предметларны еракка ыргыту, тупны чөю һәм тотып алу хәрәкәтләрен, кул чукларын, иңбаш, арка мускулларын ныгыту, умыртка баганасының сыгылмалылыгын арттыру күнегүләре ясау, спорт уеннары уйнау.

Белем бирү өлкәләренең МРК га яраклаштырылган бурычлары
(Р.К.Шәехованың мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү региональ программасы)

Танып белү үстерешле өлкәсенең бурычлары. Рус башкорт, чуваш халыкларының матур әдәбияты, халык авыз иҗаты белән таныштру, мәкаль, әйтемнәрнең мәгънәсен

аңлату, аларның сөйләмдәге урынын билгеләү. Татар, башкорт, рус, чуваш язучылары һәм шагыйрьләренең әсәрләрен башкарганда сәнгатьле сөйләмне формалаштыру. Идел буе халыкларының тарихы, культурасы, традицияләре белән таныштыру.

Сөйләм үстерү өлкәсенең бурычлары. Диалогик сөйләмне камилләштерү. Көндәлек тормышта балалар һәм өлкәннәр белән татар һәм рус телендә аралашу. Татар, рус, башкорт, чуваш халкының халык авыз иҗаты, матур әдәбияты белән таныштыру, әйтем, мәкальләрнең мәгънәсен аңлату, сәнгатьле сөйләмне формалаштыру.

Нәфасәти үсеш өлкәсенең бурычлары. Милли уен коралларының яңгырашы: (шакылдавык-рус, курай -башкорт, волынка “Сарпай”-чуваш, комуз -“кубыз”-татар) аша классик , халык, заманча музыка белән таныштыру.

Татар бизәкләре: канәфер, өчъяфрак белән таныштыруны дәвам итү; башкорт, чуваш халыклары бизәкләре, милли киемнәре турында күзаллауны формалаштыру.

Физик тәрбия үсешөлкәсенең бурычлары. Чуваш, башкорт, рус халык авыз иҗаты аша үз сәламәтлегенә, үз шәһәренә аңлы караш тәрбияләү, сәламәт яшәү рәвеше алып бару, халык уеннары белән таныштыру. Татар, рус халык уеннарын мөстәкыйль оештырырга өйрәтүне дәвам итү.

Социаль -коммуникатив үсеш өлкәсенең бурычлары. Башкорт, чуваш, рус халыкларының традицияләрен, гореф-гадәтләрен хөрмәт итү; кешелеклелек, кунакчыллык, чисталык кебек сыйфатлар, чуваш, башкорт, рус халыкларының әдәби әсәрләре аша хезмәт эшчәнлеге турында күзаллауны, төрле милләттәге яшьтәшләренә дустанә караш, мөстәкыйльлек формалаштыра.

**2.2. Турыдан -туры белем бирү эшчәнлегенең комплекслы-тематик планы. Белем бирү эшчәнлегенең тематик эчтәлеге.**

| Тема | Ае | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|
| Белем көне | сентябрь | 31.08 - 01.09. |
| Балалар бакчасы | | 04.09 – 8.09. |
| Безнең уенчыклар | | 11.09--15.09 |
| Көз. Без алтын көзне каршылыйбыз. | | 18.09--22.09 |
| Яшелчә һәм җиләк-җимешләр. | | 25.09 – 29.09 |
| Көз. Урман һәм андагы яшәүчеләр. | октябрь | 02.10 – 06.10 |
| Мин сәламәт кеше | | 9.10 – 13.10 |
| Барлык һөнәрләр дә яхшы. | | 16.10 – 20.10 |
| Туган ягым Татарстан | | 23.10 – 27.10 |
| Минем шәһәрем минем өем. | ноябрь | 30.10 – 3.11 |
| Транспорт | | 06.11 – 10.11 |
| Минем гаиләм. | | 13.11 – 17.11 |
| Әниләр көне. | | 20.11. – 24.12 |
| Йорт хайваннары | | 27.11 – 01.12 |
| Мониторинг | декабрь | 04.12 – 8.12 |
| Исәнме- кыш. | | 11.12 – 15.12 |
| Кыш килә, улый.. | | 18.12 – 22.12 |
| Кышын кошларны ашатыгыз. | | 25.12 – 29.12 |
| Кышкы каникуллар. | январь | 01.01 – 05.01 |
| Кышкы уеннар. | | 08.01 – 12.01 |
| Арктика һәм Антарктида хайваннары. | | 15.01 – 19.01 |
| Аяк, баш һәм өс киемнәре, | | 22.01 – 26.01 |
| Без кибеткә ашамлыклар алырга барабыз.. | | 29.01-– 02.02 |
| Аквариумда балыклар. | февраль | 05.02 – 09.02 |
| Бүлмә гөлләре. | | 12.02 – 16.02 |
| 23 февраль -Ватанны саклаучылар көне. | | 19.02 – 22.02 |
| 8март . | март | 26.02 – 02.03 |
| Татар халык орнаментлары белән танышу. | | 05.03 – 07..03 |
| Иҗат дөньясында. | | 12.03 – 16.03 |
| Яз башы. | | 19.03 – 23.03 |
| Язгы табигатьнең дөньясы. | апрель | 26.03 – 30.03 |
| Мониторинг. | | 02.04 – 06.04 |
| Галәм. | | 09.04 – 13.04 |
| Җир көне. | | 16.04 – 20.04 |
| Бөҗәкләр. | | 23.04 – 27.04 |
| Җиңү көне. | май | 30.04 – 04.05 |
| Икмәк иленә сәяхәт. | | 07.05 – 11.05 |
| Чәчәкләр. Агачлар. | | 14.05 – 18.05 |
| Бакчада. Яшелчә бакчасында. | | 21.05 – 25.05 |
| Исәнме, җәй. | | 28.05 -31.05. |

**2.3.Уен эшчәнлегеүсеше.**

Төп максатлар һәмбурычлар.

Балаларның уен эшчәнлеге өчен шартлар тудыру. Уйный белү сәләтен,уенның үсеш алган мәдәни формаларын булдыру. Балаларда уеннарныңтөрле төрләренә карата

кызыксынуны үстерү. Балаларны төрле яклап тәрбияләү, аларның уенда гармонияле (хисси-рухи, акыл җәһәтендә, физик, сәнгати-эстетик һәм иҗтимагый-коммуникатив) үсеше.Мөстәкыйльлекне, инициативаны, иҗатны, үзкөйләнү күнекмәләренүстерү; яшьтәшләргә карата дустанә мөнәсәбәт, бергәләп эш итү, сүз куешу,мөстәкыйль рәвештә низаглы ситуацияләрне хәл итү сәләтен үстерү.Балаларда уенның барлык төрләрен оештыруда, үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен һәм нормаларын үтәүдә мөстәкыйльлек үстерүне дәвам итү.Инициатива, оештыру сәләтләрен үстерү.Коллективизм хисе тәрбияләү.Сюжетлы-рольле уеннар. Уен сюжетына тәңгәл рәвештә балаларны үзләренә төрле рольләр алырга; атрибутлар, конструкторлар, төзелеш материалы кулланырга өйрәтүне дәвам итү.Балаларда үз уеннарын үзләренчә көйләү, мөстәкыйль рәвештә уен өченҗитенкерәмәгән предметларны (театр уены өчен билетлар, сатып алу өченакча) сайларга һәм булдырырга өйрәтү.Уеннарда әйләнә-тирә турындагы күзаллауларны, әдәбият әсәрләре, мультфильмнар турындагы тәэсирләрне иҗади куллануга булышлык итү.Иҗади хыялны, үзеңнең уен ниятләреңне яшьтәшләрең ниятләре белән килештереп, бергәләп уенны үстерү сәләтен үстерү; сүз куешу, барлыкуйнаучыларның гамәлләрен планлаштыру һәм тикшерү сәләтен формалаштыруны дәвам итү.Хезмәттәшлеккә һәм үзара ярдәмләшүгә нигезләнгән мөнәсәбәтләрформалаштыру. Яхшылык теләү, яшьтәшеңә ярдәм итәргә әзер булу, уенбуенча иптәшләреңнең мәнфәгатьләре һәм фикерләре белән исәпләшү,бәхәсләрне гадел хәл итү сәләте тәрбияләү.Хәрәкәтле уеннар. Театральләштерелгән уеннар оештыруда балаларныңмөстәкыйльлеген үстерү.Сәхнәләштерү өчен мөстәкыйль рәвештә әкият, шигырь, җыр сайлау; булачак спектакль өчен кирәкле атрибутлар һәм декорацияләр әзерләү; үзаравазифаларны һәм рольләрне бүлешү сәләтен камилләштерү.Образны гәүдәләндерүдә иҗади мөстәкыйльлек, эстетик зәвык; артистлык күнекмәләрен үстерү. Тәэсир итү чараларын (поза, ишарәләр, мимика,интонация, хәрәкәтләр) кулланырга өйрәтү.Театрга карата мәхәббәт тәрбияләү. Балаларның театральләштерелгәнэшчәнлегендә театрның төрле төрләрен (бибабо, бармак, банка, картинкалар, перчатка, курчак театрлары һ.б.) киң куллану.Театраль куелышлар, видеоматериаллар карау аша театр культурасы күнекмәләрен тәрбияләү, театр сәнгатенә тарту. Балаларга театр, театр һөнәрләре турында сөйләү.Театраль тәэсир итү чаралары (яктылык, грим, музыка, сүз, хореография,декорацияләр һ.б.) белән тудырылган сәнгать образларын аңлауга ирешергәөйрәтү.Дидактик уеннар. Балаларны төрле дидактик уеннар уйнарга өйрәтүнедәвам итү (лото, мозаика һ.б.). Уеннар оештыру, алып баручы ролен башкарусәләтен үстерү.Үз гамәлләрен алып баручы һәм уенның башка катнашучылары гамәлләре белән яраштырырга өйрәтү. Уенда тапкырлыкны, куелган бурычнымөстәкыйль хәл итү сәләтен үстерү.Балаларны кайбер дидактик уеннар («Шаулавычлар», «Кыштырдавыклар»һ.б.) булдыруга җәлеп итү. Сиземләү сәләтләрен үстерү һәм ныгыту.Уенда мәктәпкә әзерлек өчен кирәкле сыйфатлар: ирекле тәртип, ассоциатив-образлы һәм логик фикерләү, күзаллау, танып белү активлыгы чагылугаһәм үсүгә булышлык итү.

## 2.4. Программаны гамәлгә ашыруның формаларын, ысулларын, алымнарын һәм чараларын тасвирлау.

*Программаны гамәлгә ашыруның психологик- педагогик шартлары.*

Белем бирү тирәлеген гомуми оештыру үзенчәлекләре Үсешкә китерүче һәм бала өчен эмоциональ яктан уңайлы белем бирү мохите тудыру «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасын гамәлгә ашыруныңың мөһим шарты булып тора. Балалар бакчасында булу балага шатлык китерергә, ә белем бирү ситуацияләре мавыктыргыч булырга тиеш.

Иң мөһим белем бирү ориентирлары:

• балаларның эмоциональ иминлеген тәэмин итү;

• балаларның башка кешеләргә карата дустанә һәм игътибарлы мөнәсәбәтен формалаштыру өчен шартлар тудыру;

• балалар мөстәкыйльлеген (инициативалылыкны, автономия һәм җаваплылыкны) үстерү;
• балаларның эшчәнлекнең төрле төрләрендә формалашучы сәләтләрен үстерү.
Әлеге максатларны гамәлгә ашыру өчен педагогларга түбәндәгеләр тәкъдим ителә:
• бала шәхесенә карата ихтирам күрсәтү, аның белән һәм башка педагоглар белән үзара мөнәсәбәтләрнең демократик стилен үстерү;
• баланың үз өстенә җаваплылык алу һәм башка кешеләргә карата үз итү хисләрен белдерү өчен шартлар тудыру;
• килеп туган низагларны балалар белән бергә тикшерү, аларны хәл итәргә булышу, гомуми кагыйдәләр булдыру, бер-береңә карата ихтирам күрсәтергә өйрәтү;
• балалар белән тормышның мөһим мәсьәләләрен тикшерү, баланың үз позициясен белдерүен стимуллаштыру;
• балаларның игътибарын кешеләрнең үз карашлары һәм кыйммәтләре буенча бер-берсеннән аерылып торуларына юнәлтү, моның аларның үз-үзләрен тотышына ничек йогынты ясавын тикшерү;
• ата-аналар (законлы вәкилләр) белән Оешма педагогларының эшчәнлеге юнәлтелгән, шул эшчәнлек ирешергә тиешле ориентирларны тикшерү, гаилә әгъзаларын әлеге максатларга ирешү буенча бергәләп эш итүгә тарту.
Мәгариф оешмасында мәктәпкәчә белем бирү системасы баланың уенында һәм танып белү активлыгы үсешенә төбәлгән булырга тиеш. Оешмада инициативалылык, күңел күтәренкелеге, кызыксынучанлык һәм яңаны белү омтылышы кебек сыйфатлар чагылсын өчен шартлар тудырылырга тиеш. Белем бирү мохитен дөрес оештыру үз-үзеңә ышаныч, тормышка карата оптимистик караш үсешен стимуллаштыра, ялгышуга хокук бирә, танып белү мәнфәгатьләрен формалаштыра, хезмәттәшлек итәргә әзер булуны һәм башка кешегә авыр хәлдә ярдәм итүне хуплый, ягъни баланың уңышлы рәвештә социальләшүен һәм аның шәхесе үсешен тәэмин итә. Балалар тарафыннан өйрәнелүче темалар белем бирү эшенең максатларына — баланың сәләтләрен һәм инициативасын үстерүгә, мәктәпкәчә яшьтәге балага аңлаешлы мәдәни чараларны (күрсәтмә модельләрне һәм символларны) үзләштерүгә ирешү өчен материал булып тора. Шунлыктан белем бирү программасы гомер буе барачак уку-өйрәнү сәләте булдыруны, шул ук вакытта чынбарлыкка карата аңлы һәм иҗади мөнәсәбәттә булуны таләп иткән хәзерге җәмгыятьтә балаларны тормышка әзерләүнең нигезенә әверелә. Балалар бакчасында балага яхшы таныш көн дә кабатлана торган хәлләр тәрбия-белем бирү әһәмиятенә ия: һавада йөргәндә һәм режим моментлары вакытында бала үзенә һәм башкаларга карата мөнәсәбәтләр булдыра, инициативалы булырга һәм карарлар кабул итәргә, үзенең фикерләвен һәм хыялын файдаланырга өйрәнә. Психологик-педагогик шартлароештыруда педагогның роле Баланың эмоциональ иминлеген тәэмин итү Баланың эмоциональ иминлеген тәэмин итүгә аның индивидуальлеген ихтирам итү, аның эмоциональ халәтенә карата игътибарлылык, аның үз дәрәҗәсен белү хисен хуплау хисабына ирешелә. Мәктәпкәчә учреждениедә педагоглар һәр бала үзен бәяләүләрен һәм аны ничек бар шулай кабул итүләрен; аны тыңлаячакларын һәм аңлаячакларын хис итәрлек атмосфера булдырырга тиешләр. Төркемдә эмоциональ иминлек тәэмин итү өчен педагог түбәндәгеләрне эшләргә тиеш:
• балалар белән дустанә, гаепләүләрсез һәм янауларсыз аралашу;
• балаларны игътибар белән тыңлау, аларның хисләрен аңлауны күрсәтү, аларның кичерешләрен һәм фикерләрен уртаклашырга булышу;
• балаларга үз-үзеңне тотуның конструктив вариантларын табарга булышу;
• балалар төрле мәдәни чаралар (уен, рәсем, хәрәкәт һ.б.) ярдәмендә алар өчен шәхси-мөһим, шул исәптән балалар бакчасында булган вакыйгаларга карата үз мөнәсәбәтләрен белдерә алган ситуацияләр тудыру;
• көн дәвамында балалар бергә уйнарлык һәм теләгәндә ялгыз калырлык яки кечерәк төркемдә уйнау мөмкин булган ситуацияләрне чиратлаштыру.
Баланың эмоциональ иминлеген тәэминитү өчен предмет-тирәлек мохите оештыру үзенчәлекләре. Балаларның эмоциональ иминлеген тәэмин итүөчен балалар бакчасындагы

халәт өйдәгечә диярлек булырга тиеш, шундыйочракта балалар ул шартларга тизрәк күнегәләр, үз эмоцияләрен иркен белдерәләр. Балалар бакчасының балалар өчен каралган барлык бүлмәләребала үзен уңайлы һәм иркен хис итәрлек итеп җиһазландырылырга тиеш.Уңайлы шарт — бала өчен җайлы һәм ышанычлы, ул кызыклы, яраткан эшебелән шөгыльләнә алган мохит. Мохитнең уңайлылыгы балага уңай йогынтыясаучы эмоцияләр, якты һәм кабатланмас тойгылар тудыручы сәнгати-эстетик бизәлеш белән тулыландырыла. Шундый эмоцияләр тудыручы мохиттәбулу киеренкелектән, йомыклыктан, артык борчулардан арынуга булышлыкитә, бала алдында шөгыль төрен, материаллар, урын-тирәлек сайлау мөмкинлекләре ача.

Дустанә, игътибарлы мөнәсәбәтләр формалаштыру

Балаларда кешеләргә карата дустанә, игътибарлы мөнәсәбәт тәрбияләү педагог үзе балаларга карата дустанә һәм игътибарлы булган, туган низагларны конструктиврәвештә хәл итәргә булышкан очракта гына мөмкин. Балаларда кешеләргә карата дустанә мөнәсәбәт формалаштыру өчен педагог:

• үзара тәэсир итешүнең балалар өченаңлаешлы кагыйдәләрен билгеләргә;
• кагыйдәләрне тикшерү, балаларның аларны ачыклау ситуациясен тудырырга;
• мәктәпкәчә яшьтәге өлкәнрәк балаларның яңа формалар һәм кагыйдәләр булдыру инициативасын проблемалы ситуацияләрне җайга салу өчен балалар бергәләп кагыйдәләр тәкъдим иткәндә хупларга тиеш.

Мөстәкыйльлекне үстерү

Мөстәкыйльлекне үстерү ике якны адаптив (гамәлдәге социаль нормаларны аңлау һәм аларга тәңгәл рәвештә эш итә белү һәм актив (мөстәкыйль карарлар кабул итү әзерлеге) якларны үз эченә ала. Программаны гамәлгә ашыру барышында мәктәпкәчә яшьтәге балалар үз теләк-максатларын булдыруда һәм гамәлгә ашыруда позитив социаль тәҗрибә алалар. Балалар яңалыкны, шул исәптән көн дәвамындагы үз тормышларын планлаштырганда яңа нәрсәне сынап карау омтылышларының өлкәннәр тарафыннан хупланачагын тоярга тиешләр. Бу белем бирү ситуациясе балалар мәнфәгатьләрен исәпкә алып булдырылган очракта мөмкин. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар тормышындагы үзгәрешләр исәпкә алынып, балалар төркеменең белем бирү траекториясе үзгәрергә ихтимал.

Кешенең мөстәкыйльлеге (инициативалылык, автономия, җаваплылык) өлкәннәр шартлар тудырганда, нәкъ менә мәктәпкәчә яшьтә формалаша. Балаларның мөстәкыйльлеген формалаштыру өчен педагог белем бирү мохитен алар түбәндәге гамәлләр башкара алырлык итеп төзергә тиеш:

• шәхси тәҗрибәгә таянып, төрле объектлар, шул исәптән үсемлекләр белән экспериментлар ясарга өйрәнү;
• көн дәвамында яшьтәшләре һәм төрле яшьтәгеләр төркемнәрендә булу;
• уен тирәлеген уен ситуацияләренә ярашлы рәвештә үзгәртү яки конструкцияләү;
• шәхси гамәлләрдә һәм аңлаешлы карарлар кабул иткәндә автоном хәлдә булу.

Балалар инициативасына булышлык итү өчен, педагоглар даими рәвештә мәктәпкәчә яшьтәге балалар түбәндәге күнекмәләрне үзләштерерлек ситуацияләр тудырырга тиеш:

• өлкән кеше катнашында яшьтәшләре белән мөһим вакыйгалар турында фикер алышырга;
• сайлап алырга һәм шул сайланышны нигезләргә (мәсәлән, балаларга аларның сайланышын теркәүнең махсус ысулларын тәкъдим итәргә мөмкин);
• үзләренең инициативасын (ниятләр, тәкъдимнәр һ.б.) белдерергә һәм аны нигезләргә;
• үзләренең индивидуаль һәм кечерәк төркемдәге, командадагы гамәлләрен планлаштырырга;
• үзләренең гамәлләрен индивидуаль рәвештә һәм кечерәк төркемдә, командада бәяләргә.

Барлык балалар бәйрәмнәрнең балалар инициативасын исәпкә алып оештырылуы һәм балалар иҗат иткән әсәрләрне һәм тәкъдир итүләрне импровизацияләүләрне үз эчләренә алулары мөһим. Мөстәкыйльлекне үстерү өчен предмет-тирәлек мохите оештыру үзенчәлекләре. Мохит вариантлы булырга, балалар сайлап алырга теләгән төрле

мәйданчыклардан (остаханәләр, тикшеренү мәйданчыклары, сәнгать студияләре, китапханәләр, уен урыннары, лабораторияләр һ.б.) торырга тиеш. Предмет-тирәлек мохите, балаларның мәнфәгатьләренә һәм проектларына тәңгәл рәвештә, ким дигәндә берничә атнага бер тапкыр үзгәрергә тиеш. Көн дәвамында балалар үз теләкләре буенча активлык тирәлеге (мәйданчык) сайлап алсыннар өчен вакыт билгеләү зарур.

*Ирекле уен эшчәнлеген үстерү өчен шартлар тудыру*

Уен — мәктәпкәчә яшьтә беренче барлыкка килгән иң әһәмиятле кыйммәтләрнең формаларның берсе. Уйнаганда, кагыйдәләрне аңларга һәмаларны иҗади үзгәртергә өйрәнеп, бала дөньяны бөтен тулылыгы белән —мәгънәләр һәм нормалар җәһәтендә иркен һәм хозурланып үзләштерә.

Ирекле уен эшчәнлеген үстерү өлкәннәр ярдәмен таләп итә. Бу очракта, балаларның яшенә, уен эшчәнлегенең үсеш дәрәҗәсенә, ситуация характерына һ.б. га карап, педагогның уендагы роле төрлечә булырга мөмкин. Педагог уенда актив катнашучы ролендә дә, игътибарлы күзәтүче ролендә дә чыгыш ясарга мөмкин.

Уен эшчәнлеген үстерү максатында педагоглар түбәндәгеләрне башкара белергә тиешләр:

• көн дәвамында балаларның ирекле уены өчен шартлар тудыру;

• балаларга ярдәм кирәкле уен ситуацияләрен ачыклау;

• уйнаучы балаларны күзәтү, уенда көннең кайсы вакыйгалары чагылуынаңлау;

• уен эшчәнлеге үсеш алган балаларны уен сәләте аз үскән балалардан аеру;

• уен үзгәрешсез барган очракта аның белән читләтеп җитәкчелек итү (мәсәлән, яңа идеяләр яки балалар идеяләрен гамәлгә ашыру ысулларын тәкъдим итү).

Моннан тыш педагоглар балаларның субкультурасын — балаларның аеруча типик рольләрен һәм уеннарын белергә, аларның әһәмиятен аңларга тиешләр. Тәрбиячеләр уен һәм эшчәнлекнең башка төрләре арасында үзара бәйләнеш урнаштырырга тиешләр. Эчке сәбәпләр аркасында барлыкка килгән уен, өйрәтүне оештыру чарасы булудан бигрәк — балаларның үзкыйммәтле эшчәнлеге. Уен эшчәнлеген үстерү өчен предметлы тирәлек мохите оештыру үзенчәлекләре. Уен мохите балалар активлыгын стимуллаштырырга һәм балаларның агымдагы мәнфәгатьләренә һәм инициативасына тәңгәл рәвештә даими яңартылырга тиеш. Балалар өчен уен мохитен булдыруда һәм яңартуда катнашу мөмкинлеге тудырылырга тиеш. Ата-аналарда да аны камилләштерүгә үз өлешләрен кертү мөмкинлеге булырга тиеш.

***Танып белү эшчәнлеген үстерү өчен шартлар тудыру***.Бала әйләнә-тирә дөньяны мөһим һәм кызыклы тикшерү белән мәшгуль булганда өйрәтү аеруча нәтиҗәле була. Бу тикшерү барышында бала мөстәкыйль рәвештә һәм өлкән кеше ярдәмендә ачышлар ясый. Педагог, балаларның мәгълүматны үзләштерүе белән генә чикләнмичә, балаларның танып белү активлыгы ачылу ихтималы булган ситуацияләр булдырырга тиеш. Танып белү үсешен стимуллаштыручы (ягъни балалардан аңга кабул итүне, фикерләүне, хыялны, хәтерне үстерүне таләп итүче) ситуацияләр балаларның көндәлек тормышында — һавада йөргәндә, ашаганда, йокларга яткырганда, киенгәндә, бәйрәмгә әзерләнгәндә һ.б. шартларда һәрдаим туып тора.

Балаларның танып белү активлыгын педагог түбәндәге ысуллар һәм юллар белән стимуллаштырырга мөмкин:

• балаларга даими рәвештә мәгълүматны кабатлауны гына түгел, фикерләүне таләп иткән сораулар тәкъдим итеп;

• балаларга даими рәвештә ачык, иҗади сораулар, шул исәптән төрле җаваплар бирелергә мөмкин булган проблемалы-каршылыклы ситуацияләр тәкъдим итеп;

• фикерләшү вакытында булышу-хуплау атмосферасын тәэмин итеп;

• теге яки бу ситуацияне тикшергәндә балаларга карар кылу буенча тәгаенләнү мөмкинлеге биреп;

• балаларның бер үк мәсьәлә буенча төрле караш белдерүе мөмкин булган фикер алышулар оештырып, фикерләрнең тәңгәл килмәвен күрергә ярдәм итеп;

• балаларның бәхәсләр барышын үзгәртүе ихтимал булган карашларын истә тотып фикер алышу оештырып;
• балаларга үз фикерләрендәге ялгышларны табарга ярдәм итеп;
• бәхәсләр оештырырга булышып;
• балалар өчен мәсьәләне хәл итү кыен булган очракларда өстәмә чаралар (хәрәкәтләндерү чаралары, образлы чаралар, шул исәптән күрсәтмә модельләр һәм символлар) тәкъдим итеп.
Танып белү эшчәнлеген үстерү өчен предмет-тирәлек мохите оештыру үзенчәлекләре. Мохит бай эчтәлекле булырга, балага актив тикшеренү һәм мәсьәләләрне хәл итү өчен мөмкинлекләр тудырырга, заманча материалларны (конструкторлар, сиземләү формалаштыру өчен материаллар, тәҗрибәләр үткәрү өчен җыелмалар һ.б.) үз эченә алырга тиеш.
***Проектлау эшчәнлеген үстерү өчен шартлар тудыру***.Мәктәпкәчә яшьләрдә балаларда үз уй-теләкләрен, ниятләрен булдыру һәм үз проектларын гәүдәләндерү тәҗрибәсе барлыкка килергә тиеш. Мәктәпкәчә яшьләрдә балалар тикшеренү, иҗади һәм норматив проектларны ниятләргә һәм гамәлгә ашырырга мөмкиннәр. Проектлау эшчәнлеген үстерү максатында группада балаларны проектлау гамәленә рухландыручы һәм бу гамәлне хуплаучы ачык атмосфера булдырырга кирәк. Проектлау эшчәнлеге өчен даими рәвештә вакыт билгеләү, проектларны тәкъдир итү (презентацияләү) өчен шартлар тудыру зарур. Проектлау эшчәнлеген үстерү максатында педагоглар түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:
• балаларның кызыксынуын тудыручы, тикшеренүгә омтылышны стимуллаштыручы проблемалы ситуацияләр булдыру;
• балаларның төрле ситуацияләрдә килеп туган сорауларына карата игътибарлы булу; балалар тарафыннан бирелгән сорауларга җавап йөзеннәндаими рәвештә проектта каралган белем бирү ситуацияләрен тәкъдим итү;
• балалар автономиясен хуплау: балаларга үз проект чишелешләрен күрсәтергә тәкъдим итү;
• үз ниятләрен башкарганда балаларга үз эшчәнлекләрен планлаштырырга ярдәм итү;
• балалар тарафыннан тәкъдим ителгән проект чишелешләрен тикшергәндә, күрсәтелгән һәр вариантның яңалыгына басым ясап, аларның идеяләрен хуплау;
• балаларга алар тарафыннан тәкъдим ителгән чишелеш вариантларын чагыштырырга, вариантны сайлауны нигезләргә булышу.
Проектлау эшчәнлеген үстерү өчен предмет-тирәлек мохите оештыру үзенчәлекләре. Балаларның тикшеренү һәм иҗат эшчәнлегенә стимуллаштырып, аларга күп санда мавыктыргыч материаллар һәм җиһазлар тәкъдим итәргә кирәк. Табигать һәм әйләнә-тирә — тәрбиячеләрнең һәм балаларның уртак тикшеренү эшчәнлегендә файдаланырга мөмкин булган күп кенә күренешләрне һәм объектларны үз эчләренә алган тикшеренү тирәлегенең мөһим элементлары.
*Үз мөмкинлекләреңне сәнгать чаралары аша күрсәтү өчен шартлар тудыру*.Мәктәпкәчә яшьләрдә балалар вакыйгаларны фикерләү һәм төрле мәдәни чаралар — сызыклар, төс, форма, аваз (тавыш), хәрәкәт, сюжет һ.б. ярдәмендә шул вакыйгаларга карата үз мөнәсәбәтләрен белдерү тәҗрибәсе алырга тиешләр. Балалар үз мөмкинлекләрен сәнгать чаралары аша күрсәтергә өйрәнсеннәр өчен, педагог түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:
• көн дәвамында балалар үз эшләрен иҗат итәргә мөмкин булган вакытны планлаштыру;
• эшчәнлекнең иҗади төрләре белән шөгыльләнгәндә кабул итү һәм хуплау атмосферасы булдыру.
• шөгыль өчен кирәкле техник күнекмәләрне үзләштерергә ярдәм итү һәм булышу;
• балаларның иҗади эшләре бертөрле булмаслык, аларның ниятләрен чагылдырырлык биремнәр тәкъдим итү;
• уй-теләкләрне, ниятләрне гәүдәләндерүдә һәм моның өчен кирәкле чаралар сайлауда балалар инициативасын яклау;

• мәктәпкәчә яшьтәге балалар үз иҗади эшләрен төрле төркемнәрдәге балалар һәм ата-аналар игътибарына тәкъдим итәрлек вакыйгалар, чаралар, проектлар күргәзмәләре оештыру.

Үз мөмкинлекләреңне күрсәтү өчен сәнгать чаралары аша предмет-тирәлек мохите оештыру үзенчәлекләре. Белем бирү мохите кирәкле материаллар булуын, эшчәнлекнең төрле төрләре: сынлы сәнгать, музыкауен коралларында уйнау, җырлау, конструкцияләү, актерлык осталыгы, бию, һөнәрләрнең төрле төрләре, агачтан, балчыктан әйберләр ясау һ.б. белән шөгыльләнү мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

*Физик үсеш өчен шартлар тудыру*

Физик үсеш балалар сәламәтлеге өчен бик тә мөһим, чөнки ул аларның тумыштан хәрәкәткә омтылышын гамәлгә ашыру мөмкинлеге бирә. Балаларның бердәйлеге, «Мин» образы үсеше баланың физик үсеше, аның җитезлеге, хәрәкәтчәнлеге, активлыгы белән тыгыз бәйләнгән.

Балаларның физик үсешен стимуллаштыру өчен түбәндәгеләр мөһим:

• көн саен балаларга актив хәрәкәтләнү мөмкинлеге бирү;

• балаларны куркынычсызлык кагыйдәләренә өйрәтү;

• эмоциональ кабул итүнең хәрәкәтләнү өлкәсендә барлык балаларның (шул исәптән бик үк актив булмаганнарның) активлыгы чагылышына булышлык итүче дустанә атмосферасын булдыру;

• физик үсеше төрле дәрәҗәдәге балаларга рәхәтләнеп йөгерергә, үрмәләргә, сикерергә ярдәм итүче төрле өйрәтү алымнарын куллану.

Физик үсеш өчен предмет-тирәлек мохите оештыру үзенчәлекләре. Мохит балаларның физик активлыгын, үзләре теләгәнчә хәрәкәтләнү, танып белү теләген стимуллаштырырга, хәрәкәтле уеннарга рухландырырга тиеш. Хәрәкәтле, шул исәптән махсус оештырылмаган уеннар барышында балалар уен һәм спорт җиһазларыннан файдалану мөмкинлегенә ия булырга тиешләр. Уен мәйданчыгында эре моторика үсеше өчен шартлар тудырылган булырга тиеш. Уен тирәлеге (мәйданчыкта да, бүлмәләрдә дә) үзгәрүчән булырга (уенга карап үзгәрергә, хәрәкәтләнү активлыгы өчен җитәрлек урын бирелергә) тиеш.

### 2.5.Белем бирү өлкәләренең ЭРС яраклаштырылган бурычлары

(Р.К.Шәехованың мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү региональ программасы)

**Тәрбияләү һәм белем бирү бурычлары:**

Туган йортка, балалар бакчасына, туган илгә мәхәббәт тәрбияләү. Туган шәһәрнең күренекле урыннары белән таныштыру.

Татар халкының мәдәниятенә, гореф –гадәтенә кызыксыну уяту. Декоратив – кулланма сәнгате белән таныштыру.

Рус халкының мәдәниятенә, гореф –гадәтенә кызыксыну уяту. Декоратив – кулланма сәнгате белән таныштыру.

Үткән буын иҗат иткән барлык әйберләргә ихтирам тәрбияләү.

**Танып белү үстерешле өлкәсенең бурычлары**. Рус башкорт, чуваш халыкларының матур әдәбияты, халык авыз иҗаты белән таныштру, мәкаль, әйтемнәрнең мәгънәсен аңлату, аларның сөйләмдәге урынын билгеләү. Татар, башкорт, рус, чуваш язучылары һәм шагыйрьләренең әсәрләрен башкарганда сәнгатьле сөйләмне формалаштыру. Идел буе халыкларының тарихы, культурасы, традицияләре белән таныштыру.

**Сөйләм үстерү өлкәсенең бурычлары**. Диалогик сөйләмне камилләштерү. Көндәлек тормышта балалар һәм өлкәннәр белән татар һәм рус телендә аралашу. Татар, рус, башкорт, чуваш халкының халык авыз иҗаты, матур әдәбияты белән таныштыру, әйтем, мәкальләрнең мәгънәсен аңлату, сәнгатьле сөйләмне формалаштыру.

**Сәнгати-эстетик үсеш өлкәсенең бурычлары.** Милли уен коралларының яңгырашы: (шакылдавык-рус, курай -башкорт, волынка “Сарпай”-чуваш, комуз -“кубыз”-татар) аша классик , халык, заманча музыка белән таныштыру.
**Татар бизәкләре:** канәфер, өчъяфрак белән таныштыруны дәвам итү; башкорт, чуваш халыклары бизәкләре, милли киемнәре турында күзаллауны формалаштыру.
**Физик тәрбия үсеш өлкәсенең бурычлары**. Чуваш, башкорт, рус халык авыз иҗаты аша үз сәламәтлегенә, үз шәһәренә аңлы караш тәрбияләү, сәламәт яшәү рәвеше алып бару, халык уеннары белән таныштыру. Татар, рус халык уеннарын мөстәкыйль оештырырга өйрәтүне дәвам итү.
**Социаль -коммуникатив үсеш өлкәсенең бурычлары**. Башкорт, чуваш, рус халыкларының традицияләрен, гореф-гадәтләрен хөрмәт итү; кешелеклелек, кунакчыллык, чисталык кебек сыйфатлар, чуваш, башкорт, рус халыкларының әдәби әсәрләре аша хезмәт эшчәнлеге турында күзаллауны, төрле милләттәгеяшьтәшләренә дустанә караш, мөстәкыйльлек формалаштыру.

| | Милли региональ компонентны (ЭРС) искә алып,юнәлешләрнең эчтәлеге | | |
|---|---|---|---|
| № | Белем өлкәсе | Бүлекләр | Бурычлар |
| 1 | Физик үсеш | Сәламәтлек | Хәрәкәткә, бергә уйналучы татар халык һәм рус хәрәкәтле уеннарына кызыксынучанлык тәрбияләү. Балада уңай сыйфатлар, татар һәм рус халкының сулыш гимнастикасын, физминуткаларын, күнегүләрен куллана алу күнекмәләрен формалаштыру. |
| 2 | | Физик культура | Татар һәм рус халкының хәрәкәтле уеннары белән танышу, халык уеннарына кызыксынучанлык уяту. Балаларның иҗади фикерләүләрен. Физик сыйфатларын: тизлек, осталык, чыдамлыкларын үстерү, хәрәкәт күнекмәләрен камилләштерү. |
| 3 | Социаль-Шәхси үсеш | Социальләштерү | Татарстан республикасы һәм Рәсәй турында беренче күзаллауларын формалаштыру.. Зурларга һәм яшьтәшләренә әдәпле эшдәшү, үзләрен алар белән тотнаклы тоту сыйфатларын тәрбияләү. Дуслык, дөреслек, кешелек-лелек, гаделлелек тәрбияләү. |
| 4 | | Хезмәт | Үз-үзенә үзлегеңнән һәм сыйфатлы хезмәт күрсәтүне булдыру (зурлардан башка киенү, чишенү, киемнәрне төреп – элеп кую), төркемдә һәм балалар бакчасы җирлеген тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү. Үз шәһәрнең язучылары һәм шагыйрьләре әсәр--ләрендә чагылган кешеләргә файда китерүче хезмәт төрләре турында күзаллауларын формалаштыру. Үзлегеннән хезмәт итәргә һәм зурлар эшендә катнашу теләге |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | белдергәнне бүләкләү һәм ныгыту. |
| 5 | | Куркынычсызлык | Хәвефле ситуацияләрдән чыгу юллары, беренче ярдәм күрсәтү алымнары белән таныштыру. Табигатьтәге хәвефле ситуацияләр (зарарлы үсемлекләр һәм гөмбәләр) турында белемнәрен формалаштыру.Туган шәһәр урамнарында юл йөрү кагыйдәләрен ныгыту. |
| 6 | Сөйләм үсеше | Матур әдәбият уку | Татар һәм рус фольклоры, туган шәһәр язучылары һәм шагыйрьләренең якты иллюстрацияле китаплары белән таныштыру.<br>Әсәрләрне эмоциональ кабул итүне булдыру.<br>Геройларның характерын аңлый белү күнекмәләре формалаштыру. |
| 7 | | Сөйләм телен үстерү | Балалар бакчасындагы националь культура тирәлеге аша туган телне һәм икенче телне өйрәнү күнекмәләре формалаштыру. Зурлар һәм яшьтәшләре белән сөйләшү теләге уяту. |
| 8 | Танып белү үсеше | Танып белү | Туган якның һәм Мәскәү шәһәренең күренекле урыннары, туган якның үсемлекләре, хайваннары белән таныштыру. Татар һәм рус халкының мирасына кызыксынучанлык уяту. |
| 9 | Иҗади – эстетик үсеше | Җыр | Халык уен кораллары: гармун, балалайка белән таныштыру.<br>Татар халкының кайбер бию күнегүләрен башкарырга өйрәтү |
| 10 | | Иҗади –сәнгать | Татар халкының декоратив – кулланма сәнгатенә кызыксынучанлык уяту, татар орнаменты белән әйберләрне буярга өйрәтү.<br>Иҗади –сәнгатьтә «Яфрак», «Тюльпан», «Кыңгырау чәчәге» орнаменты куллану. Городец эшләнмәләре белән танышу (бутон, купавка, розана, яфрак). Рәсемдә дымка бизәкләрен куллануны ныгыту. |

***Комплекслы – тематик план (ЭРС)***

| Ай | Физик үсеш | Социаль-шәхси үсеш | Танып-белү, сөйләм үсеше | Иҗади- эстетик үсеш |
|---|---|---|---|---|
| **Яр Чаллы, Татарстан** | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Сентябрь Октябрь | *Уеннар:* «Скок - перескок», «Карусель», «Яшелчәләр» «Төсле автомобильләр» *Имитацион уен:*«Без автобуста барабыз» | Туган шәһәр турында сөйләшү. КамАЗ турында *иллюстрацияләр карау.* *Әңгәмә:* «Минем Республикам Татарстан», «Шәһәр урамнары», «Транспортта үз-үзеңне әдәпле тоту» «Һөнәрләр» | *Әкиятләр.* «Аю һәм бабай», «Төлке һәм торна» Р. Батулла «Күчтәнәч» *Шигьрият.* Б. Рәхмәт «Әтәчкәй...» Р.Валеева «Курчаккакүлмәк бүләк иттем» Р. Миннуллин «Әни белән әти турында» *Ятлау:*Бармак гимнастикасы «Бармаклар» | *Музыка:* «Осень наступила» Л. Шигабутдинова көе *Тыңлау:* «Әпипә» «Хороводная», «Әйдә, биибез» (диск «Шома бас»). *Иҗади сәнгать:* *Әвәләү:* «Кошлар**»,** «Дустыма бүләк» *Рәсем:*«Шәһәр урамнарында», «Яулыкны бизибез» *Бәйрәм:*«Сөмбелә» |
| **Россия** | | | | |
| Ноябрь | *Уеннар.* «Диңгез шаулый», «Тавык һәм чебиләр». | Әңгәмә: «Минем илем», «Россия буенча сәяхәт», «Балаларның дусты - светофор» *Диактик уеннар.* «Светофорның өч төсе», «Балалар-җәяүлелеәр һәм балалар-пассажирлар». Рус халык костюмнарын карау | | *Җыр.* «Осень» И.Кишко сүзләре, сл. Т.Волгина көе, бишек җыры «Баю-бай» М Красина көе, М.Черной сүзләре, «Ива» А.Князькова көе. И.Токмакова сүзләре, «Дождик» М.Красева көе, Н.Френкель сүзләре *Иҗади сәнгать.* *Әвәләү:* **«**Дымка аты» *Ябыштыру.*«Матрёшкалар» (коллектив эш) *Рәсем:*«Настяга сарафан» (дымка бизәге) *Бәйрәмнәр:* «Рус халык экиятләре кичәсе» |
| Декабрь | *Уеннар* «Көн - төн», «У медведя во бору», «Светофор», «Җитез җәяүле», «Ике суык» | *Әңгәмә.* «Мәскәү шәһәре», «Россия турында сөйләшү», «Юлда үзеңне дөрес тоту» *Дидактик уен* «Мәскәүдән кунаклар», | «Мороз и заяц» «Сказка про Комара Комаровича» Д. Мамин-Сибиряк *Шигьрият* «Живи, елочка!» И.Токмакова «Белый снег пушистый» И.Суриков | «Песня о Родине» И.Дунаевский «Моя Россия» Г.Струве көе, Н.Соловьева сүзләре «Я по городу иду» А. Перескокова көе, Т.Антонова сүзләре «Скоро Новый год» И.Арсеева көе, В.Татаринов сүзләре |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | «Светик-трехцветик» Т.Александровой (Веселые картинки. №6. 2003), «Как елку наряжали» Л.Воронкова | «К нам приходит Новый год» В.Герчиккөе, З.Петрова сүзләре<br>*Иҗади сәнгать.*<br>*Әвәләү:* «Әкияти кош»<br>*Ябыштыру:* «Поясны бизәү»<br>(дымка бизәге)<br>*Рәсем:* «Рус кызының күлмәге»<br>*Бәйрәмнәр:* «Хушкиләсең, Яңа ел!»<br>«Раштуа бәйрәме» |
| **Татарстан** | | | | |
| Январь | *Уеннар* «Казлар аккошлар», «Песи һәм тычкан» | Казан шәһәре турында сөйләшү. Казан шәһәренең күренекле урыннары турында рәсемнәр карау.<br>*Әңгәмә:* «Татар халык ашлары» «Сфетофор янында машиналар»<br>*Имитацион уеннар:* «Без автобуста» «Светофор сигналларына карап юл аша чыгу» | *Әкиятләр:*«Зирәк карга» А. Гаффар. «Койрык» А. Алиш. «Куян кызы»<br>*Шигърият*<br>Г. 'Гукай. «Ак бабай»<br>Ш. Галиев. «Автобуста»<br>Б. Рәхмәт. «Асия»<br>Х. Халиков. «Хәерле иртә» | *Музыка:*татар халык музыкаль коралы «Гармун” белән танышу «Попляши!», «Найди свою пару» (диск «Шома бас»)<br>*Иҗади сәнгать.*<br>*Әвәләү* «Татар халкының милли ризыгы чәк-чәк»<br>*Ябыштыру* «Мендәр чигәм»<br>*Рәсем:*«Сөлге чигәм»<br>*Бәйрәм*«Нардуган» |
| **Россия** | | | | |
| Фев раль | *Уеннар:* «Көтүчеһәм көтү», «Төлке һәм тавыклар», «Үрдәкләр», «Укчы», «Чокыр аркылы сикер» | *Беседы:* «Рус телендә назлы сүзләр», «Минем туган телем», «Мин киенә беләм», «Солдат абый» «Ватанны саклаучылар көне». | *Әкиятләр:* «Төлке, бүре, аю», «Әтәч һәм ногыт борчагы» «Сказка про маму» С.Прокофьева<br>*Шигърият:* «Научу обуваться братца» Е.Благинина, «Мамин день» И.Токмакова, «Праздник мам» В.Берестов | *Музыка:*«Сапожки скачут по дорожке» А.Филиппенко көе,Т.Волгина сүзләре, «Заинька пушистый»,«Путаница» Е.Тиличева көе, К.Чуковский сүзләре, «Кошечка» В.Витлин көе, Н.Найденова сүзләре, «Бравые солдаты» А.Флиппенко көе, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | *Проза.*<br>«Про снежный колобок» Н.Калинина, «Оля пришла в садик» В.Карасева, «Звездолетчики» В.Бороздин | Т.Волгина сүзләре, «Мамочка моя»А.Перескоков көе, С.Антонова сүзләре<br>*Иҗади сәнгать.*<br>*Әвәләү* «Аюлар өендә нәрсә бар?»<br>*Ябыштыру* «Чашка бизәү» (дымка бизәге)<br>*Бәйрәмнәр*«Масленица», «Муса Җәлил- татар шагыйре- герой». |
| **Татарстан** | | | | |
| Март | *Игры:*«Соры бүре», «Хәйләкәр төлке» | *Әңгәмә:*<br>«Татарстан хайваннары», «Туган ягым кошлары», «Минем туган урам»<br>*Кошларга җимлекләр әзерләү*<br>*Сюжетлы-рольле уен*нар: «Шофер», «Транспорт һәм җәяүлеләр» | *Әкиятләр:* «Ике ялкау» Г.Тукай «Су анасы»<br>*Шигърият:* Ш. Маннур. «каз бәбкәләре», А. Рәшит «Кояшлы туган ягым», Г. Зәйнашева «Сабантуй», М. Җәлил «Маэмай», «Чишмә»,<br>*Проза:*<br>М. Хасанов «Кар ява»<br>Г. Тукай. «Кайсы вакыт була?» | *Музыка:* «Парный танец», «Подружились» (диск «Шома бас»)<br>*Иҗади сәнгать.*<br>*Әвәләү* «Кошлар»<br>*Ябыштыру:*«Кызылтүшләр һәм песнәкләр»<br>*Рәсем:*«Татар экиятләрендә хайваннар»<br>*Бәйрәм:* «Нәүрүз» |
| **Россия** | | | | |
| Апрель | *Уеннар*<br>«Чыпчыклар» «Казлар - аккошлар», «Умедведя во бору. | *Әңгәмә:*<br>«Туган як агачлары», «Туган чкта үсүче чәчәкләр һәм үсемлекләр», «Урманда үзеңне тоту әдәбе», «Бүлмә гөлләрен тәрбиялибез»<br>Дидактик уеннар «Очалар, сикерәләр, йөгерәләр», «Нинди агачтан?» | *Әкиятләр:*«Лисичка-сестричка и серый волк», «Зимовье зверей» «Медведь и солнце» Н. Сладков, «Сороки» В. Осеева, «С перевернутой черепахе» М. Пляцковский, «Под грибом» В. Сутеев<br>*Шигърият:*<br>«Весна» Г. Ладонщиков, «Посидим в тишине» Е. Благинина, «А что у вас?» С. | *Музыка.*<br>«Зима прошла» Н. Метлов көе, М. Клокова сүзләре, «Ласточка» А. Перескоковкөе, С. Антоновасүзләре, «Песенка львенка и черепахи» Г. Гладков көе, С. Козлов сүзләре, «Апрель» П. Чайковский<br>*Иҗади сәнгать.*<br>*Әвәләү:* «Дымка әтәче»<br>*Ябыштыру:*«Урманда яз» (коллектив эш) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
